# ЯШЕЛ СИГНАЛГА СӘЯХӘТ



ISBN 978-5-6045858-9-4

0+

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы
Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының
ЮХИДИ идарәсе
«Юл хәрәкәте иминлеге» дәүләт бюджет учреждениесе
«Тормыш иминлеге фәнни үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе

# ЯШЕЛ СИГНАЛГА СӘЯХӘТ

татар телендә иҗат итүче яшь шагыйрьләр һәм язучылар
Республика конкурсы нәтиҗәләре буенча
җиңүчеләрнең иҗади эшләре җыентыгы

Казан
2021

УДК 373.2
ББК 74.100.5
Я 93

«Тормыш иминлеге фәнни үзәге»
дәүләт бюджет учреждениесе Гыйльми советы
тәкъдиме белән нәшер ителә

*Рецензентлар:*
филология фәннәре кандидаты, «Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институты» өстәмә һөнәри белем бирү дәүләт автоном белем бирү учреждениесенең татар теле һәм әдәбияты кафедрасы доценты *Р. Ф. Фәттахова;*
Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының ЮХИДИ идарәсе урынбасары, полиция полковнигы *Д. Р. Бикмөхәмәтов;*
«Юл хәрәкәте иминлеге» дәүләт бюджет учреждениесенең директор урынбасары *С. А. Бикчәнтәева*

Я 93 **Яшел сигналга сәяхәт** : татар телендә иҗат итүче яшь шагыйрьләр һәм язучылар Республика конкурсы нәтиҗәләре буенча җиңүчеләрнең иҗади эшләре җыентыгы / Р. Н. Миңнеханов, Н. И. Рәхмәтуллина гомуми редакциясендә. – Казан : Фолиант, 2021. – 100 б. : рәс.

Җыентык татар телендә иҗат итүче яшь шагыйрьләр һәм язучыларның «Яшел сигналга сәяхәт» Республика конкурсы призёрларының һәм лауреатларының иҗади эшләре нигезендә төзелде. Мәктәпкәчә яшьтәге балалар һәм кече яшьтәге мәктәп укучылары өчен чәчмә әсәрләр һәм шигърият тәкъдим ителде, анда юлларда иминлек кагыйдәләрен үтәү һәм балаларның юл-транспорт җәрәхәтләнүен булдырмау мәсьәләләре чагылдырылды.

Җыентык ЮХИДИ инспекторлары, мәктәпкәчә белем бирү оешмалары укытучылары, тәрбиячеләре, фәнни һәм практик хезмәткәрләре, балаларны юлларда иминлек кагыйдәләренә өйрәтүчеләр өчен тәкъдим ителә.

0+

ISBN 978-5-6045858-9-4

© «Тормыш иминлеге фәнни үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе, 2021
© «Юл хәрәкәте иминлеге» дәүләт бюджет учреждениесе, 2021

# ЭЧТӘЛЕК

**Кереш**...4
Миңнеханов Р.Н. Максатыбыз изге: юллар имин,
адымнар нык булсын! (Кереш сүз)...12
Мөхәммәтшин Р.Ф. Бәйгегә йомгак
һәм китапка кереш урынына...14
**1. Мәктәпкәчә яшьтәге балалар өчен «Яшь җәяүленең**
**дуслары» чәчмә әсәрләр номинациясе**...16
Дәүләтшина Л.Р. Юлдаш һәм Юл кагыйдәләре...16
Гатиятова Г.Р. Мактанчык КамАЗ – Алмаз...19
Әшрәпова Г.Р. Шаян белән Шук маҗаралары...24
Хәлиуллина Г.И. Төлке малае ничек итеп юл йөрү
кагыйдәләрен өйрәнгән?...28
Имамиева А.Р. Кешеләр шәһәренә сәяхәт...31
**2. Кече яшьтәге мәктәп балалары өчен «Юллар**
**безне алга дәшә» чәчмә әсәрләр номинациясе**...35
Хәбибуллина Г.Р. Камил маҗаралары...35
Гинятуллина Р.Р. Су кызының юл маҗаралары...38
Шәрәфетдинова А.Д. Тыңламаучан Әлфис
һәм аның акыллы самокаты...46
Шәрипова Г.Р. Беркеше...50
Мортазина А.Р. Тапкыр светофор
һәм ике сәяхәтче малайның маҗаралары...54
**3. Мәктәпкәчә яшьтәге балалар өчен**
**«Могҗизалы юллар» шигърият номинациясе**...60
Сафина А.Ф. Бер, ике, өч...60
Мөхәммәтгәрәева Г.Ф., Саляхова Ф.М. Коңгыз маҗаралары әкияте...64
Мөхәммәтҗанов А.Ф. Беркайчан да онытма...66
Вәлиуллин И.И. Сак булыгыз юлларда!...69
Ветошкина Э.Ф. Юл кагыйдәләрен истә тот!...71
**4. Кече мәктәп яшендәге балалар өчен**
**«Имин була күрсен юллар» шигърият номинациясе**...74
Галиева А.Р. Төнге сабак...74
Газимова Л.Г. Җәяүле идем мин дә...78
Хәмидуллин Д.Д. Тукайга ияреп...82
Камалетдинова Д.Ф. Нәниләргә нәсыйхәт...86
Мирзаянов Р.Р. Әбием теләкләре. Ярдәмче инспектор...88
Кашапова Д.Х. САКЛА.РУ...90
**Фоторепортаж**...91

# КЕРЕШ

Кешегә бала чакта салынган нигез,
яшь агачның кайрысына кисеп
язылган хәрефләр сыман,
аның белән бергә үсә,
аерылгысыз өлешен тәшкил итә.
*Виктор Гюго*

Тел – буынның гасырлык хезмәте.
Халык теле, һичшиксез,
иң төп һәм бетмәс-төкәнмәс чишмәбез.
*В.И. Даль*

Яшәсен татар әдәбияты,
Яшәсен туган тел!
*Г. Тукай*

Дөньяда бик күп телләр бар, ләкин һәр кеше өчен иң матур, иң кадерле һәм иң яраткан тел – ул туган тел. Туган тел аша без дөнья белән танышабыз. Тел – халыкларның тәҗрибәләрен үз эчендә саклый торган бер хәзинә. Ул халыкларның үткәннәрен генә түгел, шул ук вакытта аларның киләчәктәге үсеш мөмкинлекләрен дә үзендә булдыра.

Татарстан Республикасында яшәүче төрле халык вәкилләренең туган телен, мәдәниятен һәм гореф-гадәтләрен саклау һәм үстерү, республиканың күпмилләтле халкы бердәмлеген ныгыту максатларында, җәмәгатьчелек фикерен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Президенты Указы нигезендә 2021 ел – Татарстан Республикасында Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елы дип игълан ителде. Безнең төп бурычыбыз – үз телебезне, халкыбызның мәдәниятен, гореф-гадәтләрен, иң күркәм йолаларын, халкыбызның тарихын хөрмәт итү, аларны киләчәк буынга югалтмыйча тапшыру.

Соңгы елларда республикабызда транспорт чараларының саны күбәя, юлларда автобильләр хәрәкәте көннән-көн арта бара. Балалар мәктәптә укый башлаганчы ук юлларда йөри башлыйлар. Шуның нәтиҗәсендә балаларның юл-транспорт җәрәхәтләнүе дә көчәя. Ә бу исә үз чиратында балаларга мәктәпкәчә яшьтән үк юлларда үзләрен хәвефсез тоту кагыйдәләренә өйрәтү кирәклегенә басым ясый. Бала чакта алган белем һәм күнекмәләр яхшы үзләштерелә, тиз генә онытылмый, гомер буе саклана. Юл хәрәкәте кагыйдәләрен өйрәтүне тиз генә формалаштыру мөмкин түгел. Бу – катлаулы һәм

түземлелек сорый торган эш. Юл хәрәкәте иминлеге кагыйдәләрен өйрәнү эшен системага салу максаты белән бакчада күргәзмәләр, өстәмә белем бирү түгәрәкләре, ачык дәресләр, күңел ачу чаралары, юлларга экскурсияләр, автошәһәрдә дәресләр үткәрелә. Тәрбиячеләр балаларны юллардагы объектлар, транспорт чаралары, күренешләр белән таныштыралар. Балаларның сүзлек байлыгын үстерү белән беррәттән «Нинди? Кайда? Ни өчен?» сорауларына төзек җөмләләр белән җавап бирү осталыклары да үстерелә. Әти-әниләр белән бергә юлларда иминлек кагыйдәләрен өйрәтү дәресләрен үткәрәләр.

Хәзерге вакытта Татарстан Республикасында компетентлы белгеч һәм юл хәрәкәтендә катнашучыны әзерләүнең бердәм системасы эшләнгән. «Тормыш иминлеге фәнни үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе ел саен балалар, тәрбиячеләр һәм укытучыларны кагыйдәләргә өйрәтү буенча эшне дәвам итә, сценарийлар, дәресләр конспектлары, укыту-методик кулланмалар һәм әсбаплар чыгара. Балаларга кечкенәдән үк «юл әлифбасын» өйрәтү, юлда йөрү кагыйдәләрен формалаштыру – әти-әниләр, балалар бакчасы тәрбиячеләренең, укытучыларның һәм «Тормыш иминлеге фәнни үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенең бурычы.

2021 елның март аеннан алып апрель аена кадәр «Яшел сигналга сәяхәт» Республика конкурсы үткәрелде. Конкурс юлларда иминлек кагыйдәләрен үтәүне пропагандалау һәм балалар юл-транспорт җәрәхәтләнүен кисәтү, шулай ук мәктәпкәчә яшьтәге балалар һәм башлангыч сыйныф укучылары өчен әсәрләр язучы яшь шагыйрьләрне һәм язучыларны ачыклау һәм аларга ярдәм итү максатыннан үткәрелде. Конкурста 16 яшьтән алып 35 яшькә кадәрге яшь шагыйрьләр һәм язучылар катнаша ала иде.

Барлыгы Татарстан Республикасының 38 районыннан 225 иҗат эше дүрт номинациягә бүленде. Конкурста гомуми белем бирү мәктәпләре, колледжлар һәм югары уку йортлары укучылары, мәктәпкәчә белем бирү оешмалары тәрбиячеләре һәм башлангыч сыйныф укытучылары, өстәмә белем бирү учреждениеләре педагоглары, телерадиокомпания журналистлары, Пенсия фонды хезмәткәрләре, «Юл хәрәкәте иминлеге» ДБУ һәм «Тормыш иминлеге фәнни үзәге» ДБУ хезмәткәрләре катнашты.

Конкурс 3 этапта узды:

1 этап – материалларны кабул итү;

2 этап – иҗади эшләрне бәяләү;

3 этап – финал.

Конкурска барлыгы 225 иҗат эше килде:

1) мәктәпкәчә яшьтәге балалар өчен «Яшь җәяүленең дуслары» чәчмә әсәрләр – 71 эш;

2) кече яшьтәге мәктәп балалар өчен «Юллар безне алга дәшә» чәчмә әсәрләр – 20 эш;

3) мәктәпкәчә яшьтәге балалар өчен «Могҗизалы юллар» шигърият – 81 эш;

4) кече яшьтәге мәктәп балалар өчен «Имин була күрсен юллар» шигърият – 53 эш.

Конкурста катнашучыларга 250 сертификат әзерләнде һәм электрон почта аша җибәрелде (кайбер иҗат эшләренең икешәр авторы булган).

Иҗади эшләр Татарстан Республикасының 38 районыннан, шулай ук Казан шәһәреннән (50 эш) һәм Яр Чаллы шәһәреннән (4 эш) тәкъдим ителде. Киров өлкәсеннән бер эш алынды. 5 район (Әтнә, Югары Ослан, Кайбыч, Кама Тамагы, Чирмешән) эшләрен тәкъдим итмәгән. Плагиат аркасында 15 эш кире кагылды. Конкурстан тыш, яшь буенча туры килмәү сәбәпле, 25 эш каралды (Нигезләмәдә 16 яшьтән алып 35 яшькә кадәр). 18 катнашучы конкурска 2 номинациядә (проза һәм поэзия) гаризалар тапшырган. Конкурста 27 ир-ат һәм 198 хатын-кыз катнашты.

Конкурс нигезләмәсе нигезендә Эксперт советы (жюри) әгъзалары (2 нче кушымта) тарафыннан әсәрләргә эксперт бәя бирелде. Конкурсның финалына 40 тан артык иҗади эш сайлап алынды.

Иҗади эшләрдә катнашучылар әкият һәм шигырь рәвешендә, баш каһарман гамәлләре мисалында, мәктәпкәчә һәм кече мәктәп яшендәге балаларны юлларда иминлек кагыйдәләрен үтәү кирәклеге белән, велосипед, самокат, ролик тимераяк, маршрут транспорт чаралары һ.б. белән таныштыралар. Балаларда юлларда иминлек кагыйдәләрен үтәүгә уңай эмоциональ мөнәсәбәт формалаштыруның оптималь ысулы балаларның сөйләм үсеше буенча интеграцияләнгән дәресләр үткәрү, алар кысаларында балаларны уку, дөрес тавыш бирү һәм уй-фикерләрне дөрес итеп тасвирлау күнекмәләренә, өлкәннәр һәм яшьтәшләре белән диалог алып бару күнекмәләренә өйрәтә. Белем бирү өлкәләрен, төрле эшчәнлек төрләрен гармонияле берләштерү хисабына балаларда әйләнә-тирә дөньяның картинасын формалаштыра һәм коммуникатив компетентлыкны үстерә.

28 апрельдә Казан дәүләт мәдәният иститутында «Яшел сигналга сәяхәт» Республика конкурсының җиңүчеләрен бүләкләү тантанасы узды. Финалистларны һәм дәрәҗәле кунакларны вузның музыкаль һәм бию коллективлары каршы алды. Фойеда Казан, Кукмара, Мамадыш, Түбән Кама шәһәрләрендәге мәктәпкәчә белем бирү оешмаларының балаларны юлларда иминлек кагыйдәләренә өйрәтү буенча эшләренең тематик күргәзмәсе, шулай ук татар телендә балалар сәнгать әдәбияты күргәзмәсе һәм «Тормыш иминлеге фәнни үзәге» ДБУ укыту-методик әдәбияты күргәзмәсе оештырылган иде (рәс. 1).



*Рәс. 1. Казан, Кукмара, Мамадыш, Түбән Кама шәһәрләрендәге мәктәпкәчә белем бирү оешмаларының балаларны юлларда иминлек кагыйдәләренә өйрәтү буенча эшләренең тематик күргәзмәсе.*
*«Тормыш иминлеге фәнни үзәге» ДБУ ның рус һәм татар телләрендә балалар өчен һәм укыту-методик китаплар күргәзмәсе*

Конкурс финалистлары өчен Казан дәүләт мәдәният институтында иҗади мәктәп эше оештырылды, анда татар телендә әсәрләр иҗат итү буенча мастер-класс үткәрелде.

Мастер-классны алып бардылар:

1) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Татарстан Республикасы халыклары телләрен үстерү секторы мөдире, шагыйрь, драматург, Татарстан Республикасы Язучылар берлеге әгъзасы, конкурсның жюри әгъзасы Рүзәл Фәиз улы Мөхәммәтшин;

2) «Салават күпере» һәм «Сабантуй» журналларының баш мөхәррире, язучы, Татарстан Республикасы Журналистлар берлеге әгъзасы Зилә Зиннур кызы Хөснетдинова;

3) язучы, әдәби тәнкыйтьче, Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе, Татарстан Республикасы Язучылар берлеге әгъзасы, Галимҗан Хәмитҗан улы Гыйльманов;

4) филология фәннәре кандидаты, «Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институты» өстәмә һөнәри белем бирү дәүләт автоном белем бирү учреждениесенең татар теле һәм әдәбияты кафедрасы доценты, конкурсның жюри әгъзасы Рузилә Фирдәвес кызы Фәттахова (рәс. 2).



*Рәс. 2. Шагыйрьләр Рүзәл Мөхәммәтшин, Галимҗан Гыйльманов, «Салават күпере» һәм «Сабантуй» журналларының баш мөхәррире Зилә Хөснетдинова мастер-класс алып баралар*

Иҗади мәктәпнең эше түгәрәк өстәл формасында барды. Конкурсның финалистлары танылган татар шагыйрьләре һәм әдәбиятчылары белән язучы иҗаты һәм һөнәре, балалар һәм яшүсмерләр өчен әсәрләр иҗат итү үзенчәлекләре, татар филологиясе һәм юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү мәсьәләләре терминологиясе турында фикер алышу мөмкинлегенә ия булдылар (рәс. 3).

 

*Рәс. 3. «Яшел сигналга сәяхәт» татар телендә яшь язучыларның Республика конкурсының финалистлары. Иҗат мәктәбе эше*

«Үземә: «Конкурсның максаты нинди?» дигән сорау бирдем. Аның максаты – балалар сәламәтлеген, иминлеген тәэмин итү. Катнашучылар арасында балалар бакчалары тәрбиячеләре булуы сөендерде. Чөнки алар әлеге алымнарны көндәлек эшләрендә куллана. Әгәр дә хезмәтегез бер генә баланың сәламәтлеген саклап калса да, димәк, эшегез юкка түгел», – диде «Салават күпере» һәм «Сабантуй» журналларының баш мөхәррире Зилә Хөснетдинова.

Очрашуларда язучылар үзләренең иҗади һәм иҗтимагый эшчәнлеге, яраткан темалары һәм әсәр өчен уңай герой турында сөйләделәр, шигырьләр укыдылар. Кызыксыну белән сорауларга җаваплар язылды: «Әгәр техника алга китмәсә, халык күп вакытын китап укуга багышлар иде микән?», «Татар телендә язганда күп сүзләр, терминнар рус телендә кулланыла. Көннән-көн яңа сүзләр барлыкка килә. Тик татарчага тәрҗемәләре юк, булган очракта да аны каяндыр эзләргә кирәк. Көндәлек тормышка яңа сүзләр тиз генә кереп китә алмый. Сезнең карашка бу ни өчен шулай һәм бу мәсьәләне ничек хәл итеп була?». Очрашуда жюри әгъзаларының киңәшләре, финалчыларның эшләренә зур бәя бирүе, финалчыларны бик куандырды.

Казан дәүләт мәдәният институтының концертлар залында узган тантаналы бүләкләү чарасында сәламләү сүзе белән «Юл хәрәкәте иминлеге» дәүләт бюджет учреждениесе директоры Рифкат Нургали улы Миңнеханов, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министры урынбасары Минзәлия Заһри кызы Закирова, Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре буенча министры урынбасары Алла Андреевна Кондратьева, Казан дәүләт мәдәният институты ректоры Роза Шәйхәйдәр кызы Әхмәдиева, Тормыш иминлеге фәнни үзәге директоры Евгения Евгеньевна Воронина чыгыш ясадылар. Җиңүчеләр һәм дәрәҗәле кунаклар өчен иҗади номерлар белән Казан дәүләт мәдәният

институты педагоглары һәм студентлары, «Юл хәрәкәте иминлеге» ДБУ хезмәткәрләре һәм Казан шәһәре Совет районының 177 нче катнаш төрдәге балалар бакчасында тәрбияләнүчеләр чыгыш ясады (рәс. 4).



*Рәс. 4. Казан дәүләт мәдәният институты педагоглары һәм студентлары, «Юл хәрәкәте иминлеге» ДБУ хезмәткәрләре, Казан шәһәре Совет районының 177 нче катнаш төрдәге балалар бакчасында тәрбияләнүчеләрнең иҗади чыгышлары*

«Яшел сигналга сәяхәт» татар телендә яшь шагыйрьләр һәм язучыларның республика конкурсы җиңүчеләре һәм лауреатлары тантаналы рәвештә дипломнар, акчалата призлар белән бүләкләнделәр (рәс. 5). Җиңүчеләрне бүләкләү тантанасы институтның актлар залында җыр-биюләр белән үрелеп барды.



*Рәс. 5. «Яшел сигналга сәяхәт» Республика конкурсы җиңүчеләре*

Хәзерге тормыш шартларында балаларның юл-транспорт җәрәхәтләнүе күрсәткечләрен бары тик өзлексез белем бирү системасында юлларда иминлек кагыйдәләренә системалы һәм тәртипкә салынган өйрәтү ярдәмендә генә киметергә мөмкин. Балаларның иминлеген көн саен сакларга, аларны юлда йөрергә әзерләргә кирәк.

«Яшел сигналга сәяхәт» дип аталган татар телендә яшь язучыларның Республика конкурсы шуны күрсәтте: балаларны юлларда иминлек кагыйдәләренә өйрәтү мәсьәләсендә һәр педагог үз эшендә яңа фикерләр, методлар һәм формалар эзли, белем бирү һәм тәрбия бурычларын нәтиҗәле хәл итәргә тырыша.

Конкурста җиңүчеләрнең материалны балалар бакчаларында һәм мәктәпләрдә белем бирү эшчәнлегендә, тематик кичәләрдә куллану балаларда юл йөрү кагыйдәләре турындагы белемнәрне формалаштыруда, юлда игътибарлылык, ихтирам күрсәтү һәм сак булырга өйрәтүдә ярдәмлек буларак тәкъдим ителә.

# МАКСАТЫБЫЗ ИЗГЕ: ЮЛЛАР ИМИН, АДЫМНАР НЫК БУЛСЫН!

(Кереш сүз)




РИФКАТ НУРГАЛИ УЛЫ МИҢНЕХАНОВ,

*техник фәннәр докторы, профессор, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе мөхбир-әгъзасы, «Юл хәрәкәте иминлеге» дәүләт бюджет учреждениесе директоры, «Яшел сигналга сәяхәт» Республика конкурсы рәисе*


Телләрне һәм мәдәниятне саклау һәм үстерү мәсьәләсе – Татарстан Республикасында да, Россиядә дә иң мөһим социаль-мәдәни мәсьәләләрнең берсе. Хәзерге вакытта кешеләрнең башка халыкларның мәдәният призмалары аша гомумкешелек кыйммәтләренә якынаюы, милләт һәм мәдәниятара аралашырга өйрәнүләре аеруча мөһим. Туган телләрдә рухи һәм әхлакый идеалларның, кыйммәтләрнең, мәдәни байлыкларның зур потенциаллары салынган. Тел, туган телдәге әдәбият, милли театр һәм җырлардан башка халыкның җанын саклап калып булмый.

2021 ел – президентыбыз Рөстәм Нургали улы Миңнеханов тарафыннан «Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елы» дип игълан ителде. Туган тел ул – халкыбызның рухи көзгесе. Шушы телдә милләтнең бөтен балалары, гореф-гадәтләре генә түгел, үткәне, бүгенгесе, киләчәге дә. Шуңа күрә туган телне буыннар арасында югалтмыйк.

Татарстан Республикасында балаларны юлларда иминлек кагыйдәләренә өйрәтү буенча комплекслы һәм системалы эш алып барыла. Юллардагы транспорт чаралары агымын, кешеләр ташкынын ЮХИДИ һәм «Юл хәрәкәте иминлеге» дәүләт бюджет учреждениесе хезмәткәрләре тәртиптә тотарга тырышалар. Әмма бу гына җитми. Юлда йөргәндә, һәркем игътибарлы булырга һәм юлда йөрү кагыйдәләрен төгәл үтәргә тиеш. Балаларны юл йөрү кагыйдәләренә өйрәтү – заманыбызның иң актуаль мәсьәләләренең берсе. Юл йөрү кагыйдәләрен белгән һәм аларга буйсынган очракта гына без үзебезне юлларда тыныч һәм имин тота алабыз. Балаларга кечкенәдән үк «юл әлифбасын» өйрәтү, аларда юлда йөрү кагыйдәләрен формалашты-

ру – әти-әниләрнең, балалар бакчасы тәрбиячеләренең, укытучыларның һәм безнең бурычыбыз.

Республика күләмендә зур бәйге-конкурс үткәрү, һичшиксез, мактау һәм хөрмәткә лаеклы гамәл булды. «Яшел сигналга сәяхәт» иҗади конкурсының максаты – мәктәпкәчә һәм кече яшьтәге мәктәп балалары өчен татар телендә әсәрләр иҗат итүче яшь шагыйрьләргә һәм язучыларга ярдәм итү, юлларда иминлек кагыйдәләрен үтәү һәм балаларда юл-транспорт җәрәхәтләнүен булдырмау темаларын шигърият һәм чәчмә әсәрләр аша популярлаштыру.

Бу бәйге туган телне искә төшерүнең тагын бер сәбәбе булсын, без аны киләчәк буынга тапшырырга, телнең торышын һәм перспективаларын аңларга тиешбез.

Бәйгедә мәктәпкәчә белем бирү һәм тәрбия учреждениеләрендә эшләүче хезмәткәрләр, укучылар, студентлар, укытучылар, ЮХИДИ хезмәткәрләре катнашты. Конкурс шартлары буенча жюри тарафыннан уңышлы дип табылган иң яхшы шигырьләр һәм әкиятләр тупланган бу китапны нәшер итәргә ниятләдек.

«Яшел сигналга сәяхәт» конкурсында тәкъдим ителгән шигырьләр һәм әкиятләр балаларны юл йөрү кагыйдәләрен үтәү мөһимлеге белән таныштыралар. Алар киләчәктә балалар бакчаларында һәм мәктәпләрдә юл йөрү кагыйдәләрен өйрәтү, юлларда хәрәкәт иминлеген тәэмин итү, юл-транспорт һәлакәтләрен, балаларның юл-транспорт җәрәхәтләнүен кисәтү, рольле уеннар, дәресләр, иминлек сәгатьләре үткәрү, сәламәт яшәешне пропагандалау дәресләрендә файдалану өчен үзенчәлекле кулланма, методик ярдәмлек тә булыр дип ышанабыз.

# БӘЙГЕГӘ ЙОМГАК ҺӘМ КИТАПКА КЕРЕШ УРЫНЫНА



РҮЗӘЛ МӨХӘММӘТШИН,
*шагыйрь, Муса Җәлил исемендәге Республика премиясе лауреаты, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Татарстан халыклары телләрен үстерү бүлекчәсе мөдире, «Яшел сигналга сәяхәт» Республика конкурсының жюри әгъзасы*

Әдәбият беркайчан да күңел ачу, кәеф-сафа кору чарасы гына булмады. Аның миссиясе һәрвакыт киңрәк иде.

Әдәбият дәүләтләр төзеште.

Әдәбият Берлинны алышты. Фатих Кәрим яисә Александр Твардовскийның шигырьләрен искә төшереп узыйк...

Әдәбият чирәм җирне күтәреште. БАМнар, КамАЗлар корышты.

Әдәбият, ниһаять, үзе төзешкән дәүләтләрне пыран-заран китерергә көч куйды.

Шагыйрь-шогара, әдип-әдаба үзенә йөкләнгән олуг вазифаны ни рәвешле башкарып чыккан, җеген җеккә китереп эшләгәнме, сыйфатлымы – анысы турында сүз куертмыйк, максатыбыз ул түгел, факт буларак таныйк кына.

Быел уздырылган «Яшел сигналга сәяхәт» конкурсы да, асылда, алдагы җөмләләрдә тезелеп киткән чылбырның дәвамы саналырга лаеклы. Бу бәйге, бер яктан, яшь язучыларны кызыксындыру чарасы булып торса, икенче яктан, һичшиксез, әдәбият аша юл хәрәкәте иминлеге кагыйдәләренә төшендерү, юлда үз-үзеңне тоту этикетын пропагандалауның үзенә күрә бер формасы да булды.

Ләкин бу – уңай пропаганда, матур гамәл, минемчә.

Хәдистә ни диелгән әле? «Биш хәлгә тарыганчы үзгә биш хәлнең кадерен бел: картлык килгәнче – яшьлекне, хасталык килгәнче – саулыкны, бөлгенлек килгәнче – байлыкны, мәшәкать килгәнче – иреклелекне, әҗәл килгәнче – гомерне сакла». Светофорның кызыл сигналын инкяр итеп юл аша узу хакы – биш йөз сумлык штраф түгел, тулы бер (бердәндер!) гомереңдә булырга мөмкин ләбаса...

Конкурста катнашучылар да әдәби образлар, җанланган техника, әкәмәт персонажлар аша шушы гади һәм хикмәтле гыйбарәнең асылын ачарга омтыла.

Конкурсның катгый рәвештә махсус терминологияне кулланырга мәҗбүр итүе генә бераз бәхәс уятырга мөмкин. «Машина» сүзен «җиңел автомобиль транспорты» дип язу, «зебра»ны «җәяүлеләр кичүе»нә алыштыру ни дәрәҗәдә урынлы икән? Әлбәттә, методик әсбапларда терминологияне шулай кулланырга кирәктер дә. Әмма әдәбият казна телен, калыплашкан форма-төшенчәләрне яратмый. Аңа сыгылмалылык, җанлылык кирәк! Әдәбият ул – образ. «Зебра» да – образ, мәсәлән. Ә «җәяүлеләр кичүе» – образ түгел. Бәйге дәвам итә калса, шушы табигый хакыйкать, һичшиксез, исәпкә алыныр, дип ышанам.

Ә хәзергә конкурс тәмам. Нәтиҗәләре – хозурыгызда.

Актык фикерне сиңа әйтәсе, хөрмәтле укучы!

# 1. МӘКТӘПКӘЧӘ ЯШЬТӘГЕ БАЛАЛАР ӨЧЕН «ЯШЬ ҖӘЯҮЛЕНЕҢ ДУСЛАРЫ» ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР НОМИНАЦИЯСЕ

## I урын

## Юлдаш һәм Юл кагыйдәләре

*Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы «Мамадыш шәһәре «5 нче номерлы «Бәләкәч» балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем учреждениесе тәрбиячесе Лилия Рафаил кызы Дәүләтшина (рәс. 6)*

Борын-борын заманда түгел, хәзерге көннәрдә бер урманда яшәгән ди Шүрәле малае Юлдаш. Ул көннәр буе урман буйлап чабып йөргән ди. Кошлар белән уйнамакчы булган, кошлар аннан качканнар, җәнлекләр артыннан йөреп караган, алары да Юлдаштан ерак торуны кулай күргәннәр.

Берүзе уйнап туйгач, Юлдашның ялгызлыктан күңеле төшкән. Дуслар табасы, кызыклы, мавыктыргыч уеннар уйныйсы, дөнья белән танышасы килә башлаган. Һәм беркөнне ул кешеләр яшәгән шәһәргә барырга булган.

Менә Юлдаш зур шәһәргә килеп кергән. Ә монда автомобильләрнең иге-чиге юк ди. Гөж-гөж килә ди бөтен юллар. Менә зур йөк автомобильләре җир селкетеп узып китәләр, алар артыннан җиңел автомобильләр тыз-быз чабалар. Алар арасыннан җитез мотоцикллар да җилдерә. Мондый ыгы-зыгыны күреп, Юлдаш куркып калган.

Юлдаш юл аша чыккач, биек йортларга карый-карый алга таба киткән. Монда аңа төрле-төрле транспорт чаралары очраган. Әнә вертолёт очып бара икән, янынннан гына трамвай узып киткән, ә янәшәдәге елга буйлап кечкенә көймә йөзеп бара ди.

Бара торгач, Юлдаш юл чатына килеп чыккан. Светофорның кызыл сигнал янганда автомобильләр туктый икән, яшел янганда, кузгалып китәләр, ди. Җәяүлеләр үзләренә кирәк сигнал вакытында хәрәкәт итәләр икән. Ләкин кемдер дөрес йөрми...

Менә Юлдаш тукталышка килеп җиткән. Озак та тормый бер автобус килеп туктаган, һәм Юлдаш озак уйлап тормый, кереп утырган.

Автобустан төшкәч, Юлдаш юл кырыенда елап утыручы бер малайны күрде. Малай юлга ишарәләп елапмы елый иде. Шүрәле малае Юлдаш шунда автомобильләр арасында тәгәрәп йөргән тупны күреп алды һәм малайның шул тупны кызганып елаганын аңлады.

– Хәзер тубыңны китереп бирәм, – дип, Юлдаш юлга чыгып йөгермәкче булган иде. Ләкин теге малай аны туктатты:

– Юк, кирәкми. Юлга чыгарга ярамый, бу бик куркыныч. Мин бит аны ялгыш типтем, – дип елавын дәвам итте малай. Юлдашның ничек тә аны тынычландырасы килде һәм кесәсендә урман чикләвекләре бар икәнлеге исенә төште. Бер уч чикләвек сузып, Юлдаш:

– Мин Шүрәле малае Юлдаш, ә син кем? – дип сорады.

– Мин – Фәрит, – диде малай, күчтәнәчне кесәсенә салып. – Ник син шулай юл уртасына йөгереп чыгарга уйладың? Син юл йөрү кагыйдәләрен белмисеңмени?

– Юк, ә нәрсә соң ул? Өйрәт әле, – дип сорады Юлдаш.

– Эх, син, Шүрәле, – диде Фәрит, – киттек, мин сиңа бер әйбер күрсәтәм.

Шуннан соң бу ике яңа дус Фәритләргә киттеләр. Анда малайлар «Юл кагыйдәләре» дигән китап карадылар. Анда юл билгеләре бирелгән иде.

Шул көннән башлап, Юлдаш белән Фәрит җан дусларга әйләнделәр. Юлдаш урманнан Фәритләргә кунакка килеп йөрде. Фәрит тә ял көннәрендә Юлдашка кунакка бара иде. Беркөнне Фәрит дусты янына велосипед белән килде. Аны күргәч, Юлдаш бик шатланды. Фәрит Шүрәле малаен велосипедта йөрергә өйрәтте. Юлдаш бик тиз өйрәнде һәм урман сукмаклары буйлап рәхәтләнеп җилдерде. Фәрит:

– Юлдаш дустым, шәһәр юлларында велосипедта болай йөрергә ярамый! – диде.

– Ә нәрсә була? Киттек шәһәргә, – дип кычкырды Юлдаш һәм, педальләрне тиз-тиз әйләндереп, шәһәргә юнәлде.

Шулай итеп, Юлдаш велосипедта йөрү кагыйдәләрен дә өйрәнде. Ләкин аның автомобильгә дә утырып карыйсы килә иде. Нишләргә? Фәритнең Кәбир исемле абыйсы бар иде. Ул «Лада-Гранта» дигән автомобиль белән йөри, Фәрит шул абыйсын искә төшерде:

– Әйдә, Кәбир абыйларга! Аның автомобиле бар!

Дуслар килгәндә, Кәбир абый подъезд янында тора иде. Фәрит:

– Сәлам, Кәбир абый! Бу – минем яңа дустым Юлдаш. Аның әле бер дә автомобильгә утырып караганы юк. Безне үз автомобильдә йөрт әле, зинһар! – дип абыйсына эндәште.

– Яңа дуслар табу – бик яхшы эш, энем, – диде абыйсы, – ләкин балаларны автмобильдә имин йөртү өчен нәрсәләр кирәк икәнен беләсезме соң сез?

– Юл йөрү кагыйдәләрен белергә кирәк! – дип бертавыштан җавап бирде малайлар.

– Ул гына түгел шул. Иң мөһиме – автокәнәфи кирәк! – диде Кәбир абый. – Бәхетегез бар икән, минем шундый ике кәнәфием бар, рәхим итегез, балалар! – дип, дусларны сөендерде.

Малайлар автокәнәфиләргә кереп утырдылар, иминлек каешларын эләктерделәр һәм юлга чыктылар.

Юлдашка автомобильдә йөрү бик ошады. Ул тәрәзәдән тирә-юньне күзәтеп барды. Менә фонтан, агачлык, менә – һәйкәл. Көтмәгәндә автомобиль кинәт кенә туктады. Фәрит белән Юлдашның башы ирексездән алга таба иелде. Нәрсә булды соң? Кәбир абыйлары автомобильдән төшеп, алгы тәгәрмәч янына иелде һәм кечкенә песи баласын алып, малайларга бирде:

– Менә юл йөрү кагыйдәләрен белмәүче песи баласы, – диде. – Тәгәрмәч астына әздән генә эләкмичә калды.

Песи баласы бик нык калтырый һәм илереп мияулый иде. Фәрит аны өенә алып кайтып юды, сөт эчерде. Шуннан соң Фәрит белән Юлдаш юл кагыйдәләрен төгәл үтәргә сүз бирделәр һәм башкаларны да өйрәттеләр.




*Рәс. 6. I урын – Дәүләтшина Л.Р., Мәктәпкәчә яшьтәге балалар өчен «Яшь җәяүленең дуслары» чәчмә әсәрләр номинациясе*

**Фикер алышу өчен сораулар:**

1) Юл ничә өлештән тора?

2) Юл йөрү билгеләре ни өчен кирәк?

3) Автомобильләр хәрәкәт итә торган юлда уйнарга ярыймы? Ни өчен?

4) Юл чатларында юл хәрәкәтен җайга салучы корылма ничек атала? Ул ни өчен кирәк?

5) Транспорт чаралары нинди төркемнәргә бүленә?

6) Транспорт чараларында нинди геометрик фигуралар күрәсез?

7) Җәяүлеләргә юлны кайсы өлештә аркылы чыгарга ярый?

8) Юлның җәяүлеләр йөри торган өлеше ничек атала?

9) Маршрут транспорт чарасын көтә торган махсус урын ничек атала?

10) Маршрут буенча хәрәкәт итүче транспорт чарасы ничек атала?

11) Маршрут транспорт чарасында баручылар пассажирлар үзләрен ничек тотарга тиеш?

12) Нинди кисәтүче юл билгеләрен беләсез?

13) Ике тәгәрмәчле моторсыз транспорт чарасы ничек атала?

14) Велосипедта йөргәндә имин хәрәкәт итү өчен нинди махсус киемнәр кияргә кирәк?

15) Караңгы вакытта автомобиль йөртүчеләр сезне күрсен өчен киемгә нәрсәләр беркетелә?

16) Автомобильдә балаларга имин йөрүне ничек тәэмин итәргә?

17) Автокәнәфи ни өчен кирәк?

18) Сез Юлдашны нинди итеп күз алдына китерәсез, рәсемен ясагыз.

## II урын

## Мактанчык КамАЗ – Алмаз

*Казан шәһәре Совет районының*
*«Катнаш төрдәге 159 нчы номерлы балалар бакчасы»*
*муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем учреждениесе*
*тәрбиячесе Гүзәл Ринат кызы Гатиятова (рәс. 7)*

Татарстанның Яр Чаллы шәһәрендә урнашкан «КамАЗ»лар тудыру йортында, өр-яңа, ялтырап торган, матур бер КамАЗ дөньяга килә. Аңа Алмаз дигән исем бирәләр.

Юлларга чыгу белән, кояш нурларында матурлыгын күреп, нәни Камаз үз-үзенә бик соклана:

– Карагыз әле, мин нинди матур! Тирә-юньдә, миңа тиңнәр юк монда! Беркемдә дә юк мондый зур, кап-кара көпчәкләр, ялтырап торган кузов, ул тәрәзәләрем, көзгеләрем дисеңме... Искиткеч!

Шулай итеп, Алмаз бик озак мактанып, үзенә сокланып туйганнан соң, юлда әйләнеп, үзен башкаларга да күрсәтеп кайтмакчы була. Әлбәттә, ул юл йөрү кагыйдәләрен дә, юлда да йөри белми. Кузгалып китүгә үк, ул бар көченә куалый. Башка автомобильләр, җәяүлеләр, йортлар, аннан куркып, үзләре юл бирәләр икән. Ә КамАЗ беркемне күрми дә, белми дә ди:

– Күрәсезме?! Мин нинди матур, ялтырап торам һәм бик җитез! Киттек! Алга! – дигән дә, кычкырып җыр сузып җибәргән:

Йөгерәм мин юллардан,
Бип-бип-бип...
Көпчәкләрдән ут чыга,
Дип, дип, дип...
Карагыз миңа, нинди матур,
Кабинам саргылт-кызыл!
Бип-бип-бип!
Миңа тиңнәр юк! –
Бит-бит-бит...
Куркытмый мине җиле-яңгыры,
Ыжгырып барам, юлны тутырып,
Биип, биип, бииип!!!

Алмазга бик күңелле икән. Чөнки ул юлда үзен ничек теләгән, шулай тоткан, кая чабасы килсә, шунда чапкан ди. Шулай бик күңелле генә очып барганда, кинәт КамАЗ кемнеңдер тавышын ишетеп алган:

– Әй, бәләкәч, әкренрәк! Торып тор!

Нәни КамАЗ уңга караган – беркем дә юк, сулга караган – беркем юк... Өскә караса, анда, зур Күтәрткеч Кранны күреп алган.

– Кая чабасың син, бәләкәч? Кая кереп барганыңны күрмисеңме әллә? – дип ачулы карашны ташлаган Кран.

– Мин бер кая да кермим, бары тик чаптырып кына йөрим, – дигән Алмаз елмаеп. Минем кебек ялтырап торган КамАЗны бар дөнья күрергә тиеш – дип, күкрәген киереп куйган ул.

– Син бит йөри белмисең! Юл йөрү кагыйдәләрен белмәгән автомобильләр, юлга чыгарга тиеш түгел. Күрәм, син әле бик кечкенә, сиңа автомәктәптә укып, юл йөрү таныклыгы алырга кирәк башта, – дип кисәткән Кран.

– Фи, миңа кирәк түгел! Мин таныклыксыз да бик яхшы һәм оста йөрим! – дигән дә, мактанчык КамАЗ, тиз генә кузгалып китмәкче булган...

– Монда юл юк! Күрәсеңме, «махсус билге» куелган! Монда төзелеш эшләре бара, – дигән Кран каршы төшеп, һәм салмак кына КамАЗга арты белән борылган.

– Иии, уйлап та бирмим! Кирәкми миңа бернинди кагыйдәләр дә, махсус билгеләр дә... Миңа болай да рәхәт! Ул Кранга телен күрсәткән дә, газына каты итеп басып, ыжгыртып китеп тә барган. Һәм янә җыр сузган:

Миннән матур КамАЗ юк!
Бип-бип-бип.
Кагыйдәләр мин белмим
Бит-бит-бит...

Миннән барсы да курка,

Биип-биип-биип!

Чөнки мин йөртәм оста

Бик-бик-бик!!!

Ул шул хәтле каты чапкан, хәтта аның алгы фараларында йортлар, җәяүлеләр, светофорлар, кибетләр, белдерүләр, рәшәткәләр бер-бер артлы секунд эчендә үтеп торганнар... Зур йортлар бик аптырап:

– Ай-яй тәртипсез КамАЗ бу! Карагыз моның очуына! – дип үзләре кырыйга кереп, КамАЗга юл биреп, баш селкеп калалар икән.

Иске светофор да, бәрелеш булмагае дип, тизрәк КамАЗга яшел сигнални кабызып уздыра.

Бер зур бина Алмазга юл биреп, артыннан кычкырып кала:

– Синең болай каты йөрүеңнән бәла чыгуы бар, балам, зинһар, әкренрәк йөри күр!

– Ничек телим – шулай чабам, кая телим – шунда очам! Китегез юлымнан! Юкса таптатам!

КамАЗ үзен бик тәртипсез тотканын аңламаган да, ул барсына да үзен күрсәтергә, ничек чаптырып йөри алганын белгертергә тиеш дип уйлаган.

Юл чатында ялгыз гына, иске карт Капка тора икән. Капка авыр сулап:

– Карагыз инде сез моның очып килүенә! Минем бит селкенерлек тә хәлем юк, эргәләрем шыгырдый, ләкин баганаларым җирдә нык утыралар. Гафу итегез, мин юл бирә алмыйм, әйләнеп узсын, – ди дә карт Капка, күзләрен әкрен генә аска тошерә.

...Бах-ба-бах, бип-бип-бип, ой-ой-ой!..

Килеп кера мактанчык КамАЗ иске Капкага...

– Иптәш Инс-пеек-тоор!!! – дип кычкыра карт Капка. – Килегез әле бире?!

КамАЗ бик каты куркуга кала. Ул күзләрен чытырдатып йома да әкрен генә артка чигенә башлый...

– Нәрсә булды монда? – ди, килеп җиткән ЮХИДИ хезмәткәре.

– Менә бу КамАЗ юл йөрү кагыйдәләрен бөтенләй белми, – диде Капка.

Инспектор бик җитди итеп КамАЗга карый да:

– Рәхим итеп, минем артымнан барыгыз, – ди. Камаз полиция автомобиле артыннан әкрен генә тәгәри икән, һәм, үз-үзенә пышылдап, моңсу гына җырлап җибәрә:

Бип-бип-бип...

Ах, ялгыштым бит,

Мине алып киттеләр

Белмимен нишләтерләр...

Әгәр гафу итсәләр,
Бип-бип-бип...
Вәгъдә бирәм, башка алай
Эшләмәмен дип, дип...

Һәм нәни мактанчык КамАЗ, бик куркыныч булмасын дип, күзләрен каты итеп йомып куя... Ә ачып җибәргәч, бик нык аптырый. Ул зур, якты бер бүлмәдә, парта артында утыра икән. Аның янында кечкенә «Лада», «Нива», ә арткы рәттә зур Йөк төяү автомобиле һәм тагын бик күптөрле автомобильләр утыра ди. Алмаз үзенең автомәктәптә утырганын аңлап ала.

– Монда зурлар да, кечкенәләр дә укый икән! – дип куя Алмаз, зур, якты бүлмәне күзләп. – Димәк, миңа да монда, һичшиксез, белем алырга кирәк!

Шулай итеп нәни КамАЗ ярты ел буе мәктәптә бик тырышып укый, барлык кагыйдәләрне дә әйбәтләп өйрәнә. «Махсус билгеләрнең» нәрсә аңлатканын ул инде хәзер бик яхшы белә.

– Син хәзер тулысынча юлларда йөрергә лаексың, менә синең юл йөрү таныклыгың, – диде Инспектор КамАЗга, пластик карта сыман бер нәрсә сузып.

Алмаз бик шатлана, зур рәхмәтләрен укып, ул юлга ашкына... Саф һавада инде ярты ел булмагангамы, әллә инде башка сәбәп беләнме, КамАЗ инде дөньяга башка төрле карады. Аның күзе юлга төште. Автомобильләр, бер-бер артлы тезелеп, светофор сигналларның вакытында туктап, әкрен генә агылалар иде. КамАЗга үзенең элек кылган тәртипсезлекләре өчен бик оят булып китте. Хәзер ул үзенә сокланмый да, мактанмый да, үзен җитди, зур КамАЗлар кебек тота.

Менә ул салмак кына газына басып, әкрен генә кузгалып китте дә, олы юлга чыгып, башка автомобильләр арасында урын алды. Ул һәр «юл билгеләре»нә игътибар итеп, барлык кагыйдәләр таләп иткәнчә барды юлда. Менә аның таныш тыкрыгы...

– Исәнмесез, хөрмәтле Кран әфәнде! – дип кычкырды Алмаз, оялчан гына өскә карап.

– Хәерле көн! – дип сәламләде аны Кран, салмак кына аның ягына борылып.

– Минем, сезнең белән эшлисем килә, мине ком ташучы итеп ала алмассызмы икән? – диде ул гаепле генә.

– Хм, син бит гел ашыгасың, кагыйдәләрне үтәмисен, аннары... синең бу ялтырап торган кузовларың комга буяла бит, – диде Кран көлемсерәп.

– Гафу итегез мине... Моннан соң мин андый ялгышлар эшләмәм. Менә минем юл йөрү таныклыгым да бар хәзер, – дип Камаз таныклыгын Кранга күрсәтте.

– Әә, алай икән! Яхшы, рәхим итеп эшләп кара алайса, – диде Кран.

– Бик зур рәхмәт Сезгә!

Шуннан бирле Алмаз алдынгы, тырыш, эшчән итеп күрсәтте үзен. Хәзер инде ул беркайчан да юл йөрү кагыйдәләрен бозмады. Киресенчә, аның ялгышларын башкалар кабатламасын дип, яшь автомобильләргә үзенең киңәшләрен биреп, ашыкмаска, игътибарлы булырга өндәп торды.




*Рәс. 7. II урын – Гатиятова Г.Р., Мәктәпкәчә яшьтәге балалар өчен «Яшь җәяүленең дуслары» чәчмә әсәрләр номинациясе*

**Фикер алышу өчен сораулар:**

1) Балалар, без нинди әкият белән таныштык?
2) Алмазның юлында нинди геройлар очрый?
3) КамАЗ үзен юлда дөрес тотамы? Ни өчен?
4) Кран Алмазга нинди киңәш бирә? КамАЗ Кранны тыңлыймы?
5) КамАЗ автомәктәпкә ничек килеп эләгә?
6) Автомәктәптә укып чыккач Алмаз үзгәрәме?
7) Балалар, сез ничек уйлыйсыз, әкият безне нәрсәгә өйрәтә?
8) Сез Алмазны нинди итеп күз алдына китерәсез, рәсемен ясагыз.

## III урын

## Шаян белән Шук маҗаралары

*Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының «Кукмара шәһәре 4 нче номерлы «Ләйсән» гомумүсеш төрендәге балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем учреждениесе тәрбиячесе Гөлнар Рәшид кызы Әшрәпова (рәс. 8)*

Күптән түгел, үткән көздә, Хыял илендә булган, ди, бу хәл. Үзем ул илдә бер тапкыр булмасам да, аның турында таныш җәнлекләрдән бик күп ишеткән идем. Шул Хыял иленең бер читендә урнашкан, ди, бик матур шәһәр. Исеме дә җисеменә килешле икән. Аңа матурлыгы, чисталыгы, яшеллеккә күмелеп утырганы өчен Яшел шәһәр дип исем кушканнар.

Ул шәһәрнең халкы бик итәгатьле, юмарт, тәртипле икән. Урамда очраган һәр җәнлек белән исәнләшеп, хәлләрен сорашып, мохтаҗларга ярдәм кулы сузарга гел әзер икән.

Халкы бик тырыш һәм тәртипле булганга, бу шәһәрдә юл һәлакәтләре дә бик сирәк күренеш, ди.

Ләкин көтмәгәндә, көзнең бер ямьле кичендә, Яшел шәһәрдә яман хәлләр килеп чыккан. Нәрсә булды микән дисезме? Утырыгыз иркенләп, хәзер барсын да сөйләп китәм, дусларым.

Шәһәрнең Чәчәкле урамында, ике катлы кирпич өйдә, Шук белән Шаян исемле ике улы белән Әни тычкан яшәгән. Әниләре эштә булганлыктан, тычкан балалары үзләре генә кала торган булганнар. «Балалы өйдә бар да була», – дигәндәй, безнең тычкан балалары да тик тормаганнар. Көндез мәктәптә белем алганнар, мәктәптән кайтуга, урамга уйнарга йөгергәннәр. Көндә балалар мәйданчыгында уйнау туйдырган боларны. «Инде кая барыйк микән?» – дип баш ватып утырган вакытта, Шук тычкан баласы энесенә тәкъдим ясаган:

– Әйдә, яңа салынган юл чатында уйныйбыз. Әле ул җирдә без бер дә уйнамадык, кызык булырга тиеш анда, – дигән Шук.

Абыйсының бу тәкъдименнән Шаян тычкан баласы шүрләп калган.

– Безгә мәктәптә юл чатында уйнамаска куштылар бит, автомобиль юлы уйнау өчен түгел дип аңлаттылар. Бәлкем, анда уйнарга чынлап та куркынычтыр? – дип, борчуын белдергән Шаян.

– Әй, син куркак белән бер нәрсә дә эшләп булмый инде. Әйдә, мин булганда курыкма син, бернәрсә дә булмас. Иртәгә мәктәптә дусларга сөйләрбез. Менә күрерсең, бөтенесе дә безнең батырлыкка шаккатырлар, – дип энесен тынычландырган Шук.

Шаянның, күңеле тартмаса да, абыйсы алдында куркак булып каласы килмәгән. Ул бөтен батырлыгын җыеп, абыйсы артыннан яңа юл чатына уйнарга йөгергән.

Яңа юл чатында бик озак уйнаганнар тычкан балалалары. Монда бик иркен һәм тыныч икән. Уенга бирелеп, кич җиткәнен дә сизми калган Шук белән Шаян. Шукның энесе алдында үзен көчле, зур итеп күрсәтәсе килгән, тупны шул тикле каты типкән ки, туп, очып, яңа асфальт-бетон түшәмәсе җәелгән узу өлеше уртасына килеп төшкән. Шук белән Шаян аптырап калганнар. Хәзер инде нишләргә, тупны ничек алырга? Шук, озак уйлап тормыйча, ян-ягына каранган да, юлга туп артыннан йөгереп чыккан.

Ләкин ялгышын соң аңлаган тычкан малае. Ул юлга чыгуга, борылыштан ком тутырган йөк автомобиле килеп чыккан. Караңгы төшү сәбәпле, йөк автомобилен йөртүче Бүре тычкан малаен соң күреп алган. Бүре бөтен көченә тормозга басса да, шыплап тутырылган йөк автомобиле юлдан алга таба шуыша барган, тиз генә туктый алмаган. Шук тычкан малае куркуыннан торган урынында катып калган, күзләрен зур итеп ачып, аңа таба килүче йөк автомобиленә карап торган. Тычкан баласын таптамас өчен, автомобиль йөртүчесе йөк автомобилен юл читенә борган.

Тирә-юньне яңгыратып, тормоз чыелдавы ишетелгән. Шук бик озак күзләрен ачарга куркып, узу өлешендә тубын кочаклаган килеш утыра биргән. Автомобиль кабинасыннан ачулы Бүре килеп чыккан. Ул узу өлешендә утырып торган тычкан малае янына ашыккан.

– Син, малай актыгы, нишлисең?! Нишләп юлга йөгереп чыктың? Йөк автомобиле астына керә идең бит? Сине бер дә юлда үзеңне ничек тотарга кирәклеге турында өйрәтмәделәрмени?

Шул вакытта абыйсы янына Шаян килеп җиткән. Энесенең тавышын ишетеп, Шук күзләрен ачкан. Ул бик каты дерелди, тотлыга икән.

– Мин... Мин... Мин автомобильне күрмәдем. Мин бит тупны гына алырга чыккан идем, – дип тотлыга-тотлыга акланырга тотынган Шук.

– Бүре абзый, син минем абыйны гафу ит инде. Ул шулай буласын белмәде, – дип, Шаян да сүзгә кушылган.

Аларның тирәсендә шактый автомобиль җыелган. Сигналлары кушылган юл сакчылары хезмәте автомобиле дә килеп җиткән. Автомобильдән ЮХИДИ хезмәткәре төшеп, тычкан балалары янына ашыккан.

– Нәрсә булды монда? Нишләп юл хәрәкәтен тоткарлыйсыз?

– Менә шушы тычкан баласы узу өлешенә туп артыннан йөгереп чыкты. Киемендә яктылык кайтаргычлар да юк, шуңа бик соң күреп алдым мин аны, – дип, булган хәлләрне сөйләп бирергә ашыккан Бүре.

– Юл чатында уйнау, узу өлешенә йөгереп чыгу, караңгы вакытта яктылык кайтаргычсыз йөрү куркыныч икәнлеген белмисезме әллә сез? Ничек

шулай юлда үзеңне тотарга була? Әгәр дә Бүре әфәнде вакытында туктый алмаса, нинди аяныч хәлләр буласын аңлыйсызмы? – дигән ЮХИДИ хезмәткәре.

Тычкан балалары, башларын аска иеп, эндәшми тик торганнар.

Шул вакыт эштән кайткан Әни тычкан, малайларын өй тирәсеннән тапмыйча, аларны эзләргә чыккан. «Нишләп юл чатында шул хәтле җәнлекләр җыелды микән?» – дип, ул да бирегә ашыккан. Әни тычкан, үзенең уллары узу өлешендә җәяүлене таптату белән бәйле юл транспорт вакыйгасы китереп чыгаруларын аңлагач, бик гарьләнгән. Ул Бүре, ЮХИДИ хезмәткәреннән һәм башка юл хәрәкәтендә катнашучылардан гафу үтенгән.

– Гафу итегез минем улларымны. Аларның уйламыйча кылган гамәлләре өчен мин дә гаеплемен. Ләкин ничек аларга юл йөрү кагыйдәләрен өйрәтәсе соң? – дигән Әни тычкан.

– Борчылмагыз, мин сезгә ярдәмгә киләчәкмен. Сез малайларыгызны безнең яшь хәрәкәт инспекторлары мәктәбенә укырга бирегез. Алар анда юл йөрү кагыйдәләрен өйрәнерләр, сезне дә өйрәтерләр. Киләчәктә безнең Яшел шәһәребездә тәртип сакларга ярдәм итәрләр.

– Без риза, без риза, – диешкәннәр тычкан балалары.

– Балалар, сезне балалар бакчаларында, мәктәпләрдә үз-үзеңне юлда ничек тотарга кирәклеген өйрәтәләр. Абый, апаларыгызны тыңлагыз, юл йөрү



*Рәс. 8. III урын – Әшрәпова Г.Р., Мәктәпкәчә яшьтәге балалар өчен «Яшь җәяүленең дуслары» чәчмә әсәрләр номинациясе*

кагыйдәләрен белегез һәм үтәгез. Сез узегезне юлларда дөрес тотсагыз, без дә, ЮХИДИ хезмәткәрләре, сезнең өчен тыныч һәм һәрвакыт сезгә ярдәмгә килергә әзер булырбыз, – дигән ЮХИДИ хезмәткәре.

Шулай итеп, Шаян белән Шук яшь хәрәкәт инспекторлары мәктәбенә укырга кергәннәр. Хәзер инде алар юлда йөрү кагыйдәләрен беләләр, үтиләр һәм башкаларны да өйрәтәләр икән.

Сез дә, нәни дусларым, Шук белән Шаян көненә калмагыз, юл йөрү кагыйдәләрен өйрәнегез, белегез һәм үтәгез!

Киләсе очрашуларга кадәр, дусларым!

**Фикер алышу өчен сораулар:**

1) Син Яшел шәһәр турында нәрсәләр белдең? Син аны нинди итеп күз алдыңа китерәсең?

2) Яшел шәһәрнең халкы турында син нәрсә әйтә аласың? Алар нинди?

3) Әкияттә нинди маҗаралы хәл турында сөйләнә?

4) Кем яңа салынган юл чатында уйнарга тәкъдим итте?

5) Ни өчен йөк автомобилен йөртүче Бүре тычкан малаен соң күреп алды?

6) Нишләп Бүре йөк автомобилен тиз генә туктата алмады?

7) Шук белән Шаян тычкан малайларын чагыштыр. Уртак һәм аермалы якларын тап, аларга характеристика бир. Рәсемен ясагыз.

8) Шаян белән Шук үзләренең гаепләрен таныдылармы?

9) Син язучы булсаң, әкиятне ничек итеп дәвам итәр идең?

## Мәктәпкәчә яшьтәге балалар өчен «Яшь җәяүленең дуслары» чәчмә әсәрләр номинациясе лауреатлары

### Төлке малае ничек итеп юл йөрү кагыйдәләрен өйрәнгән?

*Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Сарман урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең 9нчы сыйныф укучысы Гүзәл Илдар кызы Хәлиуллина (рәс. 9)*

Борын-борын заманда, әле мин тумаганда, яшәгән, ди, булган, ди, бер тыңлаусыз Төлке малае. Ул беркемне дә тыңламый, ди. Әнкә Төлке дә, Әткә Төлке дә малайларын нишләтергә белмичә аптыраашта икәннәр. Нәрсә генә эшләсә дә, гел киресен эшли, ди. Ашарга чакырсалар, ашыйсым килми дигән. Ярар, ашама алайса дисәләр, тамагым ачты дип елый икән. Яше барса да, бер нәрсә дә өйрәнергә дә теләмәгән.

Шул ук урманда, Төлке гаиләсенең күршесендә, Зирәк Ябалак яшәгән. Көн дә елау, кычкырышу, тавыш Ябалак гаиләсен дә ардырып бетергән. Көннәрдән беркөнне, кич белән кояш баегач, барлык балалар йокыга талгач, бу ике гаилә һава суларга чыкканнар.

Байтак вакыт тынычлыкның рәхәтен тоеп утыргач, Әткә Төлке сүз башлаган:

– Ябалак күршем, син безне гафу итә күр инде. Сез дә безнең киребеткән улыбыз аркасында зыян күрәсез. Безгә күченеп китәргә генә каладыр инде, – дигән.

Зирәк Ябалак күршесен тынычландырырга ашыккан:

– Ашыкма әле син, Төлке дустым. Уртага салып сөйләшик: проблемадан чыгу юлын бергәләп эзлик, – дигән.

Бу ике гаилә бик озак серләшкәннәр. Таң атканын да сизми калганнар. Ә иртән... беләсезме ни булган?

Хәзер иркенләп сөйлим. Җайлабрак утырыгыз.

Төлке малае йокыдан торуга, өйдә беркем дә юк икән: өй салкын, ашарга пешмәгән, ә иң мөһиме, әти-әни янда юк! Әй, елаган Төлке малае, әй, елаган. Күзләре кызарып беткән. Тик ишетүче генә булмаган. Бары өстәлдә бер язу гына тапкан ул: «Улым, без инде бик арыдык. Әниең белән бабаңнарга ял итәргә киттек. Әгәр бик сагынсаң, адресны беләсең, килерсең», – диелгән була язуда.

Әй, киреләнеп тә куя соң Төлке малае: «Бармыйм... кирәк түгел... кайтмагыз... тамагым ачты... кайда сез?...» Тик нихәл итәсең?! Җыена да Төлке малае, юлга чыгып китә.

Менә шуннан башлана мәхшәр. Юл йөрү кагыйдәләрен белмәү аркасында ниләр генә күрми ул?!

Тукта, ашыкмый сөйлим әле. Дуслар, бәлкем, сез дә ярдәм итәрсез аңа!

Капка төбенә чыгуга, әй, тотына чабарга, әй, тотына, юлда килгән транспорт чараларны күрми дә. Ахырда бер автомобильгә бәрелә язгач, аны ЮХИДИ инспекторлар туктата:

– Үскәнем, кая юл тотасың?

– Әти белән әнием янына, – ди Төлке малае, елап шешенеп беткән күзләрен угалап.

– Ярар, әйдә әле, башта кагыйдәләрне искә төшерик, – ди ЮХИДИ хезмәткәре.

Ә Төлке малае киреләнә башлый:

– Теләмим...

Тик шул чакта полиция бинасы, бәрелгән автомобильләр, әтисе белән әнисенең елаган йөзләре, шифаханә аның күз алдыннан йөгереп үтә дә:

– Телим, телим. Өйрәтегез генә, – дигәнен сизми дә кала ул.

– Өйдән чыккач та, син тротуардан гына йөрергә тиеш. Автомобильләр үткәч кенә, юлны чыгарга. Җәяүлеләр кичүе аша гына йөрергә, юлны чыкканда, башта сулга, аннан уңга, аннары тагын сулга карарга кирәклеген онытма! Исеңдә калдымы?

– Әйе, хәзер мин аны кабатлый-кабатлый барам. Онытмаска сүз бирәм! – ди дә Төлке малае, алга таба кузгала.

Аның каршында чатта, өч күзен кысып, светофор басып тора. Менә шунда ул үзенең тагын ялгышканын аңлый: «Их, никләр киреләндем икән?! Нинди сигналга алга барыйм? Тәәәәк... Миңа кызыл сигнал ныграк ошый...» Бер адым, икеее... Төлке малае күзләрен шытырдатып йома! Дөрес эшләдеме, балалар? Юк, әлбәттә! Шап итеп тормозга баскан һәм автомобильләр «чыелдашкан» тавышка әкрен генә күзләрен ача. Кырында йөртүченең ачулы йөзен күреп, тагын еларга тотына ул.

– Елама, үскәнем. Исеңдә тот: светофор кызыл сигнал сиңа күз кыса. «Ашыкма», – ди. Сарыда әзерләнсәң, яшел сигнал: «Хәрәкәт ит!», – ди, – дип йөртүче Аю абый аңа аңлата башлый.

– Аңладым, аңладым! Мин кызыл төс яратам бит. Шуңа кызыл сигнал янганда чыгыйм дигән идем.

– Ә кая барасың син?

– Бабам өенә. Анда мине әтием һәм әнием көтә. Мин бик күп нәрсәләр белдем. Их, бүтән бер ялгышлык та эшләмәс идем.

– Әйдә әле, үскәнем, илтеп куйыйм әле үзеңне. Әйдә, күрсәт миңа ул өйне.

Йөртүче Аю абый Төлке малаен үз автомобиленә утырта. Иминлек каешын эләктерергә куша.

– Монда гына ич алар, ә-ә-әнә, күрәсезме өйләрен. Тиз барып җитәрбез.

– Юк, акыллым, алай ярамый. Автомобильгә утыру белән каешны эләктерергә кирәк. Менә мин дә эләктерәм. Ул һәрберебезнең гомерен саклаучы каеш. Сакланганны саклармын дигән мәкаль дә бар. Киттекме!

Төлке малае, тыныч кына иминлек каешларын эләктереп, йөртүчегә карады. Әлеге Аю абый бик ягымлы булып чыкты. Юлда очраган һәр юл билгесен аңлатып барды.

«Кара әле, күпме икән ич алар! Ә мин элек аларның берсен дә күрмәгәнмен, белмәгәнмен. Болар барысы да кеше гомере өчен җавап бирәләр икән бит».

Шулай тыңлап һәм уйланып бара торгач, бабасы яшәгән өй янына килеп туктадылар. Өйдән автомобиль тавышына бабасы белән әбисе, әтисе белән әнисе йөгереп чыктылар.

Автомобильдән төшүче Төлке малаен күргәч, алар бер катка аптырап та калдылар.

Шат күңелле Төлке малае, аларны йөгереп килеп кочаклап, болай диде:

– Әнием һәм әтием, мин бүген бик күп нәрсәләр белдем. Күпме юл билгеләре бар икән. Аларны «тыңламасаң», бәлагә тарырга да мөмкинсең. Мин барын да истә калдырдым. Ә иң мөһиме: мин бүтән киреләнмим. Мин сезне яратам. Әйдәгез, өйгә кайтыйк әле!

Әнкә Төлке белән Әткә төлке, бер-берсенә серле генә карашып, улын кочтылар:

– Без кунакка гына килгән идек, әйдәгез, кайтабыз, – диделәр.

Шул көннән башлап алар бик бәхетле яшәгәннәр. Малай да бер дә киреләнми икән. Зирәк Ябалак киңәшләрен тотып, күршеләр дә тынычлыкта дус-тату яши башлаганнар.

**Фикер алышу өчен сораулар:**

1) Балалар, ничек уйлыйсыз: юлда «теләмим» дип кенә йөреп буламы?

2) Юлны чыкканда, нинди кагыйдәләргә нигезләнергә кирәк?

3) Ничек уйлыйсыз: иминлек каешын һәрвакытта да эләктерергә кирәкме?

4) Юл йөрү кагыйдәләрен үтәмәү нәрсәгә китерә?

5) Ә сез Төлке малае кебек булыр идегезме?

6) Ә сез әти-әни сүзен һәрчак тыңлыйсызмы?

7) Сез Төлке малаен нинди итеп күз алдына китерәсез, рәсемен ясагыз.




*Рәс.9. Хәлиуллина Г.И., Мәктәпкәчә яшьтәге балалар өчен «Яшь җәяүленең дуслары» чәчмә әсәрләр номинациясе лауреаты*

## Кешеләр шәһәренә сәяхәт

*Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы «Олимп» яшьләр үзәге муниципаль бюджет учреждениесенең яшьләр белән эшләү буенча белгече Айгөл Русил кызы Имамиева (рәс. 10)*

Светофорлар шәһәрендә нәниләр өчен бүген шатлыклы вакыйга! Ниһаять, кечкенә Яшелкүзне берничә дусты белән кешеләр яшәүче шәһәргә экскурсиягә, абый-апаларының ничек эшләүләрен күрсәтергә алып баралар.

Яшелкүз кечкенәдән кешеләр янына омтылды. Абыйсын, инде күп еллар зур трассада кешеләрнең иминлеген саклап, җиңел автомобиль транспорты һәм йөк автомобильләр туктатып җәяүлеләр кичүеннән кешеләрне юлның икенче ягына чыгарып торучы олы светофорны, эшеннән кайткан саен кешеләр турында сөйләтә иде. Абыйсы исә рәхәтләнеп сөйли, аеруча балаларны күзәтергә ярата иде ул. Яшелкүз генә аңлап бетерә алмый: нигә күзләрнең бөтенесен бергә йомып ял итеп торырга ярамый? Бер күзне генә озак йомып торсаң ара бит инде ул? Күз йомык булгач, кешеләр күренми бит инде? Шушы һәм башка сорауларны гел биреп, абыйсын туйдырып бетерде Яшелкүз. Көннәрдән бер көнне боларны ишетеп торучы әтиләренең башына

бер фикер килде: ә нигә әле бөтен нәниләргә кешеләр шәһәрен күрсәтеп кайтмаска ди? Светофорлар мәктәбендә дәресләр башланганчы вакыт җитәрлек, мәктәп бетереп, кешеләрнең юллардагы иминлеге сагында торучы абый-апаларының хезмәтен күреп кайтсалар, балаларга зыянга булмас.

Бу фикерне калган әти-әни светофорлар да хуплады.

Ниһаять, кешеләр шәһәре! Яшелкүз юлда да тәрбияче апаларын сораулары белән ялыктырып бетерде.

– Каракаш апа, ә без сез эшләгән җирне дә карыйбызмы соң?

Каракаш апалары исә күп еллар тимер юл чатында иминлек сагында торган олы яшьтәге светофор ханым иде. Үз гомерендә күпне күргән һәм светофорларның ничек эшләвеннән юлларда иминлек саклануын әйбәт аңлаучы, тәҗрибәле тәрбияче дә иде ул.

– Яшелкүзкәем, бигрәк тиктормас инде үзең. Бүген шәһәр эче юлларында булабыз, синең абыең торучы зур юлны да узабыз әле, беләсең килсә. Балалар, беләсезме, Яшелкүзнең абыйсы – кешеләрне юлдан чыгару вакытында бер генә һәлакәткә дә юлыктырмаган бердәнбер светофор, безнең шәһәребезнең горурлыгы! – монысын Каракаш апалары бөтен балаларга да җиткерде. – Киләчәктә безнең светофорлар мәктәбен бетергәч, сез дә шушы юлларда басып торырсыз, эшегезне төгәл итеп башкарып, кешеләргә бик күп файда китерерсез дип ышанып калам.

Яшелкүз абыйсын чак таныды! Өйдә гел шаярып сөйләшүче, энесе белән төрле уеннар уйнаучы абыйсы эштә бигрәк җитди икән! Кызыл һәм сары күзләрен йомып, яшел күзе белән карап җәяүлеләр кичүеннән кешеләрне чыгара, ул арада транспорт чараларын көттереп тора; сары күзен яндырып, җиңел автомобиль транспорты һәм йөк автомобиләрына кузгалырга әзерләнергә куша; кызыл күзе белән усал итеп карап, юлга чыгарга ашыгучы балаларны кисәтә. Менә нинди мөһим эшләр башкара икән аның абыйсы!

– Каракаш апа, әгәр бер үк вакытта кызыл һәм яшел күзне дә ачсаң, ни була? – дип сорап куйды шулчак Яшелкүзнең дусты Кызыл маңгай.

– Коточкыч хәлләр була балалар! – Каракаш апалары сискәнеп китте. Хәзер мин сезгә бер хәл сөйлим.

...Мин ул вакытта әле яшь идем, светофорлар мәктәбен бетергәч, мине шәһәрнең кеше иң күп үтә торган урамына эшкә куйдылар. Башта тыныч кына эшләдек, мине алыштыручы олы яшьтәге светофор апа миңа бик күп нәрсәләр өйрәтте. Көннәрдән бер көнне аны ремонтка җибәрделәр, һәм мин шушы юлда берүзем калдым. Атна буе ялсыз эшләү үзенекен итте бугай, мин юл кырыенда басып торганда йоклап китә башладым. Шулай бервакыт, үзем дә сизми, бөтен күзләремне йомганмын, йөк автомобиле кычкырткан тавышка сискәнеп, берьюлы ике күземне дә: кызылны да, яшелне дә ачып җибәрдем. Куркудан нишләргә белмим: кешеләр дә җәяүлеләр кичүенә чык-

ты, маршрут транспорт чаралары да юлда, җиңел һәм йөк автомобильләр да кузгалган. Бәхетемә, шул арада каяндыр килеп чыккан ЮХИДИ хезмәткәре үзенең юллы-юллы таягы белән әлеге мәхшәрне җайлап җибәрде, кешеләргә зыян килмәде.

– Сез аннары монда эшләмәдегезме? – гадәттәгечә, кызыксынучан Яшелкүз Каракаш апасының сөйләвен бүлде.

– Мине аннары ялга җибәрделәр, балалар. Ялдан соң инде озак елларга тимер юл чатына эшкә килдем, анда кешеләр еш үтеп йөрмәсә дә, җаваплы урын. Менә шундый хәлләргә калмас өчен, вакытында ял итәргә дә кирәк балалар. Һәм инде юл йөрү кагыйдәләрен төгәл белергә. Сез – юлларның баш сакчысы! Бик күп кеше гомерләре сезнең дөрес итеп күзләрегезне йомуыгыздан тора.

Балалар кешеләр шәһәреннән бик уйга батып кайттылар. Чыннан да светофор эше авыр һәм җаваплы икән. Светофор күзләренә игътибар итеп тормыйча юлга йөгереп чыгучы кешеләр барлыгын да күрделәр. Ә Яшелкүзнең күңелендә абыйсы шикелле горур басып торучы шәһәр юлының иң яхшы светофоры булу теләге ныгыды гына. Светофорлар мәктәбендә бик яхшы билгеләргә генә укып, теләгенә ирешәчәк ул!

Шундый хыяллары белән йокыга киткәнен сизми дә калды Яшелкүз. Әтисе исә, елмаеп йоклап ятучы нәни светофор улына карап, аңа кешеләр шәһәрен күрсәтү уе дөрес фикер булганын аңлады.



*Рәс. 10. Имамиева А.Р., Мәктәпкәчә яшьтәге балалар өчен «Яшь җәяүленең дуслары» чәчмә әсәрләр номинациясе лауреаты*

**Фикер алышу өчен сораулар:**

1) Яшелкүз һәм калган нәниләр ни өчен сөенә?
2) Кешеләр шәһәренә алар еш барамы?
3) Яшелкүзнең абыйсы кайда эшли?
4) Ул нинди эшләр башкара?
5) Әтиләре балаларга нинди бүләк ясый?
6) Кем ул Каракаш апа?
7) Ул балаларга нинди хәл турында сөйли?
8) Ни өчен юлда һәлакәт була язган?
9) Яшелкүз сәяхәттән нинди уйлар белән кайта?
10) Сезнеңчә, светофорлар эше мөһимме?
11) Әлеге әкият сезгә нәрсәсе белән ошады?
12) Сез Яшелкүзне нинди итеп күз алдына китерәсез, рәсемен ясагыз.

# 2. КЕЧЕ ЯШЬТӘГЕ МӘКТӘП БАЛАЛАРЫ ӨЧЕН «ЮЛЛАР БЕЗНЕ АЛГА ДӘШӘ» ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР НОМИНАЦИЯСЕ

## I урын

## Камил маҗаралары

*Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы*
*«Апас урта гомуми белем бирү аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнү мәктәбе»*
*гомуми белем бирү муниципаль бюджет учреждениесенең*
*11 нче сыйныф укучысы Гүзәл Ранис кызы Хәбибуллина (рәс. 11)*

Бер шәһәрдә Камил исемле малай яшәгән. Үзе алай ук начар да булмаган, тик юлда йөрү кагыйдәләрен үтисе килмәгән. Укытучылар да, әти- әнисе дә, өлкәннәр дә өйрәтеп караганнар, Камил генә колагына элмәгән. «Дөрес булмаган кагыйдәләр нәрсәгә алар? – дигән. Ә кисәтүләргә игътибар итмәгәнгә аны ачулана башласалар, ул һәрвакыт кемнедер гаепләгән, үзенә сүз әйткәнне яратмаган.

Иртән мәктәпкә барганда, юлдан күктәге каргаларны санап барган. Автомобиль йөртүчеләр ачуланса, кошларны гаепләгән. Беркөнне Камилнең тубы юлга тәгәрәгән, ул, як-ягына да карамыйча, юлга йөгереп чыккан. Шул вакытта автобус йөртүчесе туктап, аңа бик катгый кисәтү ясаган. Транспортлар йөрү өлешендә уйнарга ярамаганлыгын аңлаткан. «Ул кагыйдә дөрес түгел, юл һәркем өчен ясалган», – дигән Камил. Шулай әдәпсезләнүен дәвам иткән. Бервакыт ул кеше ышанмаслык хәлгә дучар булган.

Юл чатындагы светофорда кызыл сигнал янса да, траспорт-фәлән күренмәгәч, Камил юл аркылы чыгарга булган. Гөнаһ шомлыгына каршы, каяндыр кечерәк кенә җиңел автомобильдә, рульдә карт кына бабай пәйда булган. «Кая ашыгасың син, улым? Юл йөрү кагыйдәләре сиңа да кагыла бит. Менә хәзер минем автомобиль астына керә идең», – дип бик нык ачуланган карт кеше. «Әнә светофор гаепле инде, транспорт чаралары да булмаганда, аңарда яшел сигнал янарга тиеш иде. Дөрес булмаган кагыйдәләр шунда. Сезнең кебек карт бабайлар да рульдә йөрергә тиеш түгел. Өйдә генә утырыгыз», – озын телләнгән малай. «Әә, дөрес булмаган кагыйдәләр дисең, алайса, – дип елмайган бабай, – димәк, сиңа «Кагыйдәсез юллар» илендә яшәргә кирәктер?» Шулай дигән дә, автомобиленә утырып, күздән югалган бабай.

Ул да түгел, каяндыр көчле җил чыккан, давыл кузгалган. Камил куркудан күзләрен йомган. Бераздан күзләрен ачып як-ягына караса, бөтенләй

башка, таныш булмаган җиргә килеп чыккан. Ул юл уртасында тирә-ягын күзәткән. Монда аңа бар нәрсә дә ят булган: юллар да, йортлар да, кешеләр дә. «Нәрсә генә булды соң әле? Нинди ил турында сөйләгән икән теге бабай?» – дип уйлаган Камил.

Урыныннан кузгалмакчы булган, аның өстенә әздән генә велосипедчы малай менмичә калган. Руле белән Камилнең букчасын эләктереп, икесе бергә асфальтка егылганнар. «Кем юл уртасында велосипед белән йөри? Болай эшләргә ярамый бит!» – дип ачуланган велосипедчыны Камил. Үзе яшендәге велосипедчы мөгезле атын торгызган да: «Син кем монда? Яңа кешеме? Бу бит «Кагыйдәсез юллар» иле. Монда кем ничек тели, шулай йөри», – дип, ничек килгән булса, шулай чаптырып китеп барган.

Камил юл читенә ашыккан. Берничә адым киттеме икән, тротуардан нәкъ аның каршына ук йөк автомобиле килүен күргән. Камил аңардан чокырга сикереп кенә котылган. «Ник соң җәяүлеләр сукмагыннан кеше генә йөрми, ә автомобильләр җилдерә?» – дип кычкырган Камил ачуланып. Ул еларга җитешеп, юлын дәвам иткән. Бер урамны гына борылган икән, анда бик көчле автомобильләр ташкынына тап булган. Юлның икенче ягында үз илендә күргән карт бабай тора ди. «Туктагыз!» – дип кычкырган Камил бабайга, тик үзе берничек тә чыга алмый икән. «Җир асты юлы кайда икән соң монда?» – дип уйлаган Камил. Кызганычка каршы, бу илдә ул кагыйдә дә юк икән. Бабай да күздән югалган. Шул вакытта Камил бик куркыныч хәл күргән. Шул автомобильләр ташкынына бер кечкенә генә малай кереп киткән. Камилнең коты очкан, нишләргә белмәгән. Куллары белән болганып, күп транспорт чараларын туктаткан да малайны юлдан алып чыккан. «Тиеш булмаган урында юл аркылы чыгарга ярамый!» – дип кисәткән кечкенә малайны Камил. Ни өчен үзе генә йөрүен, әти-әнисен, өен сораган һәм озата киткән. Малай белән хушлашкач, Камилгә бик ямансу булган, үз илен сагынган. Теге карт бабайны эзләргә керешкән.

Менә юлның уң ягыннан килүче, колагына колакчын тыккан, олы гына абыйны күргән Камил. «Туктагыз!» – дип кычкырган ул аңа, ләкин абый аңа борылып та карамаган. Транспорт чаралары ничек кенә сигнал бирмәсеннәр, абый юлын дәвам иткән. «Эх, куркыныч хәл була күрмәсен, юл йөрү кагыйдәләрсез бигрәк тә авыр икән...» – дип уйлап бетерүе булган. Бер автомобильнең каты тормоз чыелдавына борылып караса, коточкыч хәлне күргән. Аңына килә алмый торганда, юлдан бер төркем малайлар чабып килүен абайлаган. Аларны туктатып: «Башта юлда йөрү кагыйдәләрен өйрәнегез, бервакытта да юлдан чапмагыз!» – дип боерган. Ә үзенә бик тә, бик тә авыр булган. Ул кычкырып елап җибәргән. «Гомерем буе юлда йөрү кагыйдәләрен үтәр идем, башка беркемгә каршы килмәс идем», – дип ялварган Камил.

Аның күзләре йомылган, нишләргә белмәгән. Юл кырыендагы бер агач төбенә барып утыруы булган, көчле җил искән, агач яфраклары шыбырдашкан. Күз ачып-йомуы булган, янында гына теге карт бабайны күргән. «Зинһар, мине үз илемә кайтар! Мин үземә мәңгелек сабак алдым!» – дигән Камил. «Яхшылабрак кара, син үз илеңдә бит», – дигән бабай. Малай шатланып, бабай белән хушлашкан һәм таныш светофорның яшел сигналын күтеп, юл аркылы чыккан да өенә йөгергән. Юллар исә аны алга дәшкән.




*Рәс. 11. I урын – Хәбибуллина Г.Р., Кече яшьтәге мәктәп балалары өчен «Юллар безне алга дәшә» чәчмә әсәрләр номинациясе*

**Фикер алышу өчен сораулар:**

1) Сез Камилне нинди итеп күз алдына китерәсез, рәсемен ясагыз.
2) Юлда йөрү кагыйдәләрен үтәргә кирәкме?
3) Малай ни өчен светофорны гаепләгән?
4) Беркөнне Камил белән нинди хәл булган?
5) «Кагыйдәсез юллар» илендә яшәве җиңелме?
6) Камил ул илдә үзен ничек тоткан?
7) Ник аңа авыр булган?
8) Ул нәрсә дип ялварган?
9) Малай үз иленә ничек кайткан?
10) Әкият нәрсәгә өйрәтә?

## II урын

## Су кызының юл маҗаралары

*Казан шәһәре Вахитов районының*
*«Катнаш төрдәге 190нчы номерлы балалар бакчасы»*
*муниципаль автоном мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе*
*тәрбиячесе Резедә Рәхимҗан кызы Гинятуллина (рәс. 12)*

Җәй – иң яхшы ел фасылы, чөнки җылы, тирә-як яшеллеккә күмелә, алгы-гөлле чәчәкләр үсә, әйләнә-тирә сихри матурлыкка күмелә. Теләгән җиргә, теләгән вакытта ял итәргә барырга мөмкин.

Бу елны Арсланның җәйге каникулы кызыклы вакыйгаларга бик бай булды. Беркөнне алар әти-әнисе белән авылдагы әби-бабасына кунакка кайтып килергә уйладылар. Арслан әнисе белән кибеткә кереп күчтәнәчләр алып чыккан арада әтисе автомобильдәге балалар өчен махсус җайланмалы автокресланы җайлап куйды. Барысы да үз урыннарына утыргач, саклагыч каешларын эләктереп куйдылар да авылга кайтып киттеләр.

Бу авыл зур да, кечкенә дә түгел. Монда тырыш, дус-тату кешеләр генә яши. Җәй көне авыл урамнары кунакка кайткан малайлар, кызлар тавышы белән шау-гөр килә. Авылның арьягыннан матур, чиста елга ага. Авылда яшәгән әби-бабайлар, елгада Су анасы, Су кызы яши, дип әйтсәләр дә, беркем дә ышанмады, чөнки XXI гасырда нинди Су анасы, Су кызы яшәсен ди инде?! Кешеләр бу сүзләрне бары тик әкият, уйдырма гына итеп кенә кабул иттеләр.

Беркөнне шундый эссе һава иде... Балалар урамда уйнап йөргәннән соң, елгада су коенып кайтырга уйладылар. Барысы да өйләренә кайтып, әби-бабаларыннан елга буена төшеп, су коенып кайтырга рөхсәт алдылар да тизрәк елгага йөгерделәр. Балалар көне буе рәхәтләнеп суда йөзделәр, кояшта кызындылар, уйнадылар, балык тоттылар. Вакыт үткәнен сизми дә калдылар. Кич җиткәч, өйгә кайтыр алдыннан малайлар барысы да соңгы тапкыр суда йөзеп чыгарга булдылар. Арслан, елгадан йөзеп чыкканда, камышлар арасында нәрсәдер ялтырап ятканын күреп алды. Якынрак йөзеп килгәч, бик матур, төрле-төрле ташлар белән бизәлгән таракны күрде. Ул бу таракны беркемгә дә әйтмичә тиз генә алды да елгадан чыгып малайлар белән өйгә кайтып китте. Бу тарак гади генә түгел, ә бик зур сихри көчкә ия булганын һәм аны Су анасының кызы Су кызы югалтканын Арслан белми иде әле...

Икенче көнне иртән иртүк бик көчле җил чыкты, кояшны кап-кара болытлар бик тиз арада каплап алды. Арсланның әти-әнисе, көннең шулай тиз

үзгәрүенә бик гаҗәпләнеп, куркып калдылар. Алар тиз генә җыендылар да шәһәрдәге өйләренә кайтып киттеләр.

Бу вакытта Су кызы әнисе бүләк иткән таракны бөтен җирдән эзли-эзли арып беткән иде инде. Әгәр әнисе таракның югалганын белсә, каты кайгырачак бит. Шул вакытта Су кызы елга төбендә озак еллар буе яшәүче Зирәк Ташбака барлыгын исенә төшерде дә шунда йөзеп китте. Зирәк Ташбаканы ул тиз эзләп тапты. Янына якынрак килеп, үзенең хәлен сөйләп бирде.

– Кызым, сиңа ярдәм итми булмас, китапханәдән тылсымлы китапны алып кил әле, – диде Зирәк Ташбака. Су кызы китапханәдән тылсымлы китапны көч-хәл белән алып килде дә:

– Бик авыр икән бу китап, – дип әйтте.

– Бу китапта тылсым көче күп, шуңа күрә авыр ул, – диде Зирәк Ташбака.

Китапны ачып карагач, таракны шәһәр малае алып киткәнен белеп алдылар. Су кызына хәзер бер минут та тоткарланып тормыйча, шәһәргә барып, шул малайны табарга кирәк.

– Рәхмәт, Зирәк Ташбака, син миңа бик ярдәм иттең, – диде Су кызы, елгадан йөзеп чыкты да шәһәргә китеп барды...

Су кызы шәһәргә килеп җиткәч, үзен сихри дөньяга килеп эләккән кебек хис итте. Аның шулкадәр күп өйләрне, киң юлларны, серле таблицалардагы матур итеп ясалган билгеләрне, юл өстенә буй-буй сызылган сызыкларны һәм бер кабынып, бер сүнгән ике, өч төсле сәер җайланманы беркайчан да күргәне юк иде. Су кызының авыл юлларында сирәк кенә булса да транспорт чараларын очратканы бар иде, ә шәһәрдә алар бертуктаусыз йөреп торалар икән. Монда нинди генә транспорт чарасы юк: зурысы да, кечкенәсе дә, төрле төстәгесе дә, дүрт, алты, сигез тәгәрмәчлесе дә, мөгезлесе дә, тимер рельслар өстеннән йөри торганнары да бар икән. Алар уң якка да, сул якка да йөреп торалар.

– Транспорт чаралары бер дә туктамагач, бу юлны ничек йөреп чыгармын икән? – диеп Су кызы бик озак юл читендә уйланып басып торды да ашыга-ашыга юл аша чыга башлады.

Транспорт чарасын йөртүчеләр, юл аша чыгып баручы кызны күргәч, ни эшләргә белмичә, сигналларын кычкыртып үттеләр. Бәхеткә, Су кызы юл һәлакәтенә очрамый калды! Аны юл уртасында куркып басып торганын юл хәрәкәтенең яшь инспекторлары күреп алалар һәм сак кына юл аша чыгаралар.

– Ни өчен юл хәрәкәте кагыйдәләрен бозып йөрисең? – дип сорадылар юл хәрәкәтенең яшь инспекторлары.

– Нинди кагыйдәләр??? Мин бер нинди кагыйдә дә белмим, шәһәргә Арслан исемле малайны гына эзләп килдем, – диде куркып кына Су кызы.

– Ярар, борчылма, без хәзер сиңа юл кагыйдәләрен өйрәтербез, ә аннан соң Арсланны эзләп табарга да ярдәм итәрбез. Син тыңлап тор һәм исеңдә калдыр!

– Җәяүлеләр, транспорт һәлакәтенә юлыкмас өчен, юл хәрәкәтендә иминлек кагыйдәләрен үтәргә тиешләр. Юл кырыеннан хәрәкәт иткән очракта юл читенә урнаштырылган махсус билгеләргә игътибар итәргә кирәк. Бу билгеләр транспорт йөртүчеләргә һәм җәяүлеләргә юлның үзенчәлекләре турында хәбәр итәләр, хәрәкәт итү юнәлешләрен күрсәтәләр. Транспорт чаралары юлның рельссыз юл йөрү өлешеннән йөри, ә җәяүлеләр юлның җәяүлеләр йөрү өлеше – тротуардан йөриләр.

– Ни өчен юлның транспорт чаралары үтеп йөрү өлешен берничә өлешкә бүлеп юл тамгалары сызганнар? – дип сорады Су кызы.

– Әлеге тамгалар ярдәмендә транспорт чаралары бер-берсенә капма-каршы төрле юнәлешләрдә хәрәкәт итә ала, әле махсус урыннар да бар, аннан җәяүлеләр юлны куркынычсыз рәвештә чыга ала.

– Җәяүлеләр юл аша курыкмыйча чыга торган урыннар да бармы?

– Әйе, җәяүлеләр юл аша чыга торган урынны «җәяүлеләр кичүе» диеп атыйлар. Юл аша чыгар алдыннан иң элек-сулга, аннан-уңга кара, аннан соң тагын бер тапкыр сул ягыңа кара, автомобильләрнең барысы да туктап, сине юл аша чыгарга теләгәнеңне күргәч һәм туктагач кына, юл аркылы чыгарга ярый.

– Минем беркайчан да бер кабынып, бер сүнгән ике, өч төсле сәер җайланманы күргәнем юк иде. Нәрсә соң ул, ни өчен анда басып тора?

– Исеңдә калдыр! Бу җайланма «светофор» – ул юлда безнең иң якын дустыбыз. Ул яктылык сигналлары ярдәмендә җәяүлеләр һәм транспорт чаралары хәрәкәтен көйли. Җәяүле светофорындагы яшел сигнал кабынганын күрсәң, юл аркылы чыгарга ашыкма. Светофорның яшел төсле сигналы – тулысынча иминлек дигән сүз түгел әле. Юл аша чыгар алдыннан башта сул ягыңа, аннан соң уң ягыңа кара, аннан соң тагын бер тапкыр сул ягыңа кара – автомобильләрнең барысы да туктап, синең үтүеңне көтүенә ышангач кына кузгал. Әгәр юл читендә җәяүлеләр өчен светофор булмаса, транспорт чаралары светофорына, яки юл хәрәкәтен көйләүченең сигналына кара. Атомобильләр тиз генә килеп җитмәс әле дип, светофорның кызыл төсле сигналы янганда, беркайчанда юл аша чыкма, – дип кисәтәләр юл хәрәкәтенең яшь инспекторлары.

– Ә кич җиткәч, җәяүлеләрне транспорт чарасын йөртүчеләр юл аша чыкканын күрә аламы соң?

– Тәүлекнең караңгы вакытында яки һава торышы начар булган вакытта җәяүлеләрнең киемнәрендә яктылык кайтаргыч җайланмалары (сигнал бирә торган жилетлар, ябыштырып, эләктереп куя торган тамгалар, шнурлар,

брелоклар, беләзекләр) булырга тиеш. Транспорт чараларының фараларыннан яктылык кайтаргыч элементларына ут төшкәч, җәяүлеләрне вакытында күреп, тизлекне киметеп туктап кала алалар.

– Бик зур рәхмәт сезгә, хәзер инде, юл аша чыкканда, иминлек кагыйдәләрен үтәрмен, сак йөрермен, игътибарлы булырмын! Бүген бик күп юл йөрү кагыйдәләрен өйрәндем, хәзер башкаларга да өйрәтә алам! – дип сөенде Су кызы.

– Кагыйдәләрне исеңдә калдырганга без бик шат. Ә хәзер Арсланның өенә барсак та ярый. Киттекме?

– Әйдә!

Юл хәрәкәтенең яшь инспекторлары белән Су кызы Арсланны тиз эзләп таптылар. Арслан Су кызын күргәч, куркып калды. Су кызы ни өчен килгәнен, нинди сынаулар аша үткәнен сөйләп биргәннән соң, Арслан үзенең гаепле булуын аңлап алды. Су кызына таракны китереп бирде дә, гафу үтенде. Шул көннән соң Арслан белән Су кызы иң якын дуска әйләнделәр. Авылга кайткач һәрвакыт очрашырга сүз бирделәр.

Кич җиткәч, юл хәрәкәтенең яшь инспекторлары Су кызын авылдагы елгага кадәр кайтарып киттеләр. Су кызы өенә кайткач, тизрәк үзенең дуслары янына барды. Ул дусларына, шәһәргә барып кайтканын сөйләде. Юлларда барысы да исән-сау йөреп, хәвеф-хәтәр булмасын өчен барысына да юл хәрәкәтенең иминлек кагыйдәләре турында сөйләп бирде.

**Фикер алышу өчен сораулар:**

1) Бу әкият кем турында?

2) Арслан таракны алып дөрес эшләгәнме?

3) Син Арслан урынында ни эшләр идең?

4) Тарак Су кызына ни өчен кадерле?

5) Су кызы ни өчен шәһәргә килгәч гаҗәпләнеп кала?

6) Су кызы нинди юл кагыйдәләрен боза?

7) Юл аша чыкканда, син үзеңне ничек тотарга тиеш?

8) Су кызына ярдәмгә кемнәр килә?

9) Җәяүлеләр, транспорт һәлакәтенә юлыкмас өчен, юл хәрәкәтендә иминлек кагыйдәләрен үтәгәндә нинди билгеләргә игътибар итәргә тиеш?

10) Транспорт чаралары һәм җәяүлеләр юлның кайсы өлешеннән йөриләр?

11) Юл читендә җәяүлеләр өчен светофор булмаса, юл аша ничек чыгарга ярый?

12) Җәяүлеләр юл аша чыга торган урынны ничек атыйлар?

13) Тәүлекнең караңгы вакытында һәм һава торышы начар булган вакытта җәяүлеләрнең киемнәрендә нәрсә булырга тиеш?

14) Көндәлек тормышта син юл аша ничек чыгасың?

15) Су кызы тагын нинди юл хәрәкәте кагыйдәләре белән танышты?

16 Су кызы Арслан янына кем белән барды?

17) Арслан үзенең гаебен таныдымы?

18) Су кызы өенә кайткач, кем янына барды?

19) Арслан юл хәрәкәтенең иминлек кагыйдәләре турында дусларына сөйләдеме?

20) Бу әкият сине (сезне) нәрсәгә өйрәтте?

21) Сез Су кызыны һәм Арсланны нинди итеп күз алдына китерәсез, рәсемен ясагыз.

## Велосипедта һәм роликлы тимераякларда йөрү кагыйдәләре турында әкият

Җәй көне шәһәр малае Арслан белән булган хәлдән соң, авылда яшәгән кешеләр дә су коенырга төшкән саен, Су анасы үзенең кызлары белән йөзеп үткәнен күрә иделәр...

Беркөнне Су анасы елгада олы кызы – Су кызына 10 яшь тулган көнне бәйрәм итте. Арслан да бу бәйрәмгә әти-әнисе белән килгән иде. Алар Су кызына велосипед, ә сеңлесе Тамчыга роликлы тимераяклар бүләк иттеләр. Кызлар, бүләкләрне күргәч, бик сөенделәр.

Икенче көнне Арслан елга буена төшеп, Су кызы һәм Тамчыны уйнарга чакырды. Ул көне буе кызларны велосипедта һәм тимераякларда йөрергә өйрәтте. Әзрәк уйнаганнан соң, Арслан кызларга:

– Бабай миңа озак тоткарланма, утын ташыйсы бар дигән иде. Миңа кайтырга кирәк, – дип әйткәч, кызларның кәефе төште.

– Көнне бушка уздырасыбыз килми, якында гына парк бар дип әйттеләр, безгә анда барырга ярыймы? – дип сорады Су кызы.

– Ярый, ләкин юлда хәрәкәт иткәндә, иминлек кагыйдәләрен бозмагыз, сак булыгыз. Хәзер мин сезгә паркка бару юлын аңлатып, кәгазьгә сызып бирәм, – диде Арслан. Ул Су кызы белән Тамчыга паркка бару юлын ясап аңлатты да, кызлар белән саубуллашып, өенә кайтып китте.

Арслан өенә кайтып киткәч, Су кызы белән Тамчы кәгазь битенә бик озак карап тордылар.

– Бигрәк ерак икән бу парк, бу юл белән барсак, вакытыбызны гына әрәм итәбез, әйдә, кыска юлдан гына барабыз, – дип әйтте Су кызы. Тамчы апасына каршы килмәде...

Су кызы белән Тамчы колакчыннарын киделәр дә, музыканың тавышын көчәйтеп йөреп тә киттеләр. Тротуардан да, юлларда дә йөреп бардылар, саклану экипировкасын да кимәгән иделәр.

Шулай бара торгач, җәяүлеләр кичүенә килеп җиттеләр. Светофорның яшел сигналы янып-сүнеп тора иде. Су кызы сеңлесен велосипедның рамына утыртты да, велосипедыннан төшмичә, юлны җәяүлеләр кичүе аша чыга башлады. Кызлар кычкырып сөйләшеп бардылар, җәяүлеләрне төртеп уздылар, юл читенә чыгып җиткәндә, башка җәяүлеләргә тротуарга чыгарга комачауладылар. Көтмәгәндә, борылыштан йөк автомобиле килеп чыкты, ул кызларны күргәч, кайсы якка барыйм икән дип, әле уң якка, әле сул якка боргаланды. Әле дә ярый, йөк автомобиленең йөртүчесе тәҗрибәле иде, ул вакытында туктап кала алды. Кызлар нишләргә дә белмичә, куркуларыннан бер урында басып калдылар.

Бу вакытта автомобильдә юл хәрәкәтенең яшь инспекторлары үтеп бара торган була. Алар кызлар янына килеп:

– Юл хәрәкәте кагыйдәләрен бозып, кая барасыз? – дип сорадылар.

– Паркка барып, велосипедта һәм роликлы тимераякларда йөреп кайтасыбыз килгән иде, – диде Су кызы.

Юл хәрәкәтенең яшь инспекторлары:

– Авыл юлларында да һәрвакыт юл хәрәкәте кагыйдәләрен үтәргә кирәк. Без хәзер сезгә велосипедта һәм роликлы тимераякларда йөрү кагыйдәләрен өйрәтербез, ә сез исегездә калдырыгыз, – дип әйттеләр.

Иң элек, юл аша чыгар алдыннан, велосипедның төзеклеген тикшер. Велосипедыңда артта калган юлны күрсәтә торган көзге, сигнал, ак, кызыл, кызгылт сары төстәге яктылык кайтаргычы, кызыл төс таратучы фонарь булырга тиеш.

Юлны җәяүлеләр кичүе аша чыкканда, автомобиль үтеп бара торган булса, аны үткәреп җибәр.

Юл кырыенда автомобиль туктап басып торса, яки кечкенә генә куаклар үсеп утырса, алар артында качып утырырга ярамый, чөнки автомобильне йөртүчеләр җәяүлеләрне ерактан күреп торырга тиешләр.

Велосипедчы, җәяүлеләр кичүенә килеп җиткәч, велосипедтан төшеп рульне ике кулы белән тотып, үзен үткәреп җибәргәннәрен күргәннән соң гына, велосипедын үзе белән янәшә төртеп барырга тиеш.

Җәяүлеләр кичүеннән чыкканда, башка җәяүлеләргә комачаулама!

Велосипед һәм роликлы тимераякларда йөргәндә, колакчыннарны кияргә ярамый, бернәрсә дә ишетми калырга мөмкин.

Махсус җиһазландырылмаган велосипедта 7 яше тулмаган балаларны утыртып йөрергә ярамый.

7–14 яшьтәге балаларга велосипедта бары тик тротуар, җәяүлеләр кичүеннән, велосипед өчен махсус юлдан, велосипедчылар һәм җәяүлеләр сукмагыннан, җәяүлеләр зонасы чикләрендә генә йөрергә ярый.

Велосипед һәм роликлы тимераякларда йөргәндә, шлем, тез һәм терсәк калканнары, перчаткалар кияргә, киемдә яктылык кайтаргыч элементлары булырга тиеш.

Бу кагыйдәләрне кызлар игътибар белән тыңлап тордылар, үзләренең күпме юл кагыйдәләрен бозганнарын аңладылар. Барысын да истә калдырып, башка юл кагыйдәләрен бозмаска вәгъдә бирделәр. Юл хәрәкәтенең яшь инспекторлары кызларга шлем, тез һәм терсәк калканнары, перчаткалар, киемдә яктылык кайтаргыч элементларын бүләк иттеләр. Юл хәрәкәтенең яшь инспекторлары кызларга:

– Велосипедта һәм роликлы тимераякларда паркка тиз генә барып җитә алмассыз, автобуска утырып барыгыз. Моннан ерак түгел тукталыш бар, автобуслар паркка кадәр еш йөреп торалар, – дип әйттеләр. Кызлар, риза булып, тукталышка киттеләр, чөнки аларның тизрәк паркка барып, велосипедта һәм роликлы тимераякларда йөреп кайтасылары килә иде.

Тукталышка килеп җиткәч, кызлар чабып йөрделәр, качышлы уйнадылар. Автобус килеп җиткәч, кызлар ишек төбендә басып торучы әбиләргә юл бирмичә, беренче керергә тырышып этә-төртә кереп киттеләр. Яннарында таяк белән басып торучы әбигә, утырып барырга урын бирмәделәр. Автобус кузгалып киткәч, тәрәзәне ачып, башларын тәрәзәдән чыгарып юлны карап бардылар. Колакчыннарын киеп җыр тыңладылар, кычкырып җырладылар. Аннан соң туңдырма ашый башладылар, ашап бетергәч, кулларын урындыкка сөрттеләр дә, бер утыргычтан икенчесенә күчеп, йөртүче янына барып аңа комачауладылар.

Парк тукталышына килеп җиткәч, Су кызы белән Тамчы, автобустан төшкәндә, юл хәрәкәтенең яшь инспекторларын очраталар.

– Без маршрут транспорт чарасында нинди дә булса кагыйдәне боздыкмы әллә?! – дип сорадылар.

– Әлбәттә. Ничек шулай тыйнаксыз һәм тәрбиясез булырга мөмкин!!! – дип җавап бирде юл хәрәкәтенең яшь инспекторы.

– Безнең шундый зур транспорт чарасына утырып йөргәнебез юк иде... Ә нинди кагыйдәләр соң алар? – дип сорады Су кызы.

– Транспорт чарасын йөртүчеләр дә, җәяүлеләр дә, пассажирлар да, велосипедта һәм роликлы тимераякларда йөрүчеләр дә юл хәрәкәте кагыйдәләрен белергә һәм үтәргә тиеш. Хәзер мин сезгә җәяүлеләр һәм пассажирлар белергә тиешле берничә төп кагыйдәне өйрәтәм, – диде юл хәрәкәтенең яшь инспекторы.

Маршрут транспорт чарасын һәм таксины автомобильләр йөри торган юлдан бераз күтәрелгән утрырту мәйданчыкларында тукталыш зонасында, алар булмаса, тротуарда яки юл кырыенда көтәргә рөхсәт ителә.

Транспорт чарасын көткәндә, тукталышта чабып йөрергә ярамый!

Җәяүлеләр, транспорт чарасына кереп утыргач, пассажирга әйләнәләр һәм, кая барасылары килсә, шунда кадәр бара алалар.

Транспорт чарасына утыргач, як-ягыңа кара, бәлки янәшәңдә олы кешеләр, балалы аналар бардыр, аларга урын бир!

Маршрут транспорт чарасында кычкырып сөйләшмә, колакчыннарыңны сал, йоклап барма, бернәрсә дә ашама, тәрәзәдән башыңны чыгарып барма, салон буенча чабып йөрмә, йөртүчегә комачаулама.

Башка кешеләрне дә хөрмәт ит, синнән соң да бу транспорт чарасына утырып йөрүчеләр бар бит, – дип әйтте юл хәрәкәтенең яшь инспекторы.

Хәзер инде Су кызы белән Тамчы юл йөрү кагыйдәләрен бик күп өйрәнделәр, башкаларга да өйрәтә алалар. Кызлар юл хәрәкәтенең яшь инспекторларына рәхмәт әйтеп, паркка китеп бардылар.

Паркка баргач, кызлар рәхәтләнеп велосипедта һәм роликлы тимераякларда йөрделәр. Тирә-юньдәге кешеләргә дә игътибарлы булдылар. Бик күп малайлар һәм кызлар белән таныштылар. Кич җиткәч, башка көнне очрашырга сүз биреп, малайлар һәм кызлар өйләренә кайтып киттеләр. Су кызы белән Тамчы да тукталышка басып торган маршрут транспорт чарасына утырып өйгә кайтып киттеләр.

Кызлар өйгә кайткач, бер-берсен бүлдереп, әниләренә бүгенге юл маҗараларын сөйләп бирделәр. Алар, юл хәрәкәтенең яшь инспекторлары ярдәме белән, юлларда үз-үзеңне тоту кагыйдәләре турында бик күп мөһим һәм кызыклы мәгълүматлар белән танышканнарын сөйләделәр.

Өлкәннәр һәм балалар да, җәяүлеләр дә, транспорт чарасы йөртүчеләр һәм пассажирлар да бу кагыйдәләрне белергә һәм үтәргә тиеш! – дип әйтте Су кызы.

**Фикер алышу өчен сораулар:**

1) Бу әкияттә нинди геройлар бар?

2) Су кызына ничә яшь тулган?

3) Су кызы белән Тамчыга Арсланның әти-әнисе нәрсә бүләк иттеләр?

4) Кызларны велосипедта һәм тимераякларда йөрергә кем өйрәтте?

5) Су кызы белән Тамчы ни өчен паркка кыска юлдан барырга уйладылар?

6) Кызлар ни өчен һәм нинди юл йөрү кагыйдәләрен бозалар?

7) Бу очракта син (сез) нишләр идең(гез)?

8) Кызларга кемнәр ярдәм итә?

9) Юл хәрәкәтенең яшь инспекторлары кызларны нинди юл хәрәкәте кагыйдәләре белән таныштыралар?

10) Кызлар паркка велосипед һәм роликлы тимераякларда йөреп баралармы? Тагын нинди юл маҗарасына тап булалар?



*Рәс. 12. II урын – Гинятуллина Р.Р., Кече яшьтәге мәктәп балалары өчен «Юллар безне алга дәшә» чәчмә әсәрләр номинациясе*

11) Кызлар, парк тукталышына килеп җиткәч, кемнәрне очраталар?

12) Җәяүлеләр һәм пассажирлар тукталышта һәм транспорт чарасында нинди кагыйдәләрне бозмаска тиеш?

13) Бу әкият сездә нинди хис уятты?

14) Бу әкият сезне нәрсәгә өйрәтте? Көндәлек тормышта бу кагыйдәләрне кулланырсызмы?

## III урын

## Тыңламаучан Әлфис һәм аның акыллы самокаты

*«Тормыш иминлеге фәнни үзәге»*
*дәүләт бюджет учреждениесенең*
*сәркатип-референты Алия Дамир кызы Шәрәфетдинова (рәс. 13)*

Зур һәм шактый иске йортта Әлфис исемле малай яши. Күптән түгел Әлфиснең туган көне иде һәм аңа 8 яшь тулды. Бүләкләр арасында иң ошаганы – әти-әнисе бүләк иткән самокат. Ике көпчәкле самокат шундый матур, яхшы,

җиңел, яшел төстә, тиз йөри. Самокат белән берлектә саклагыч җайланмалар да бар: баш, тез, терсәк саклавычлар һәм фликерлар.

– Улым, автомобиль йөри торган юлда самокатта йөрергә һәм барганда самокат белән җәяүлеләргә комачауларга ярамый. Шулай ук саклангыч җайланмаларыңны кияргә онытма. Ишегалдында гына йөр дип кисәтте әтисе.

– Әйе, аңладым, – диде малай.

Бу сөйләшү Әлфиснең бер колагыннан кереп, икенчесеннән чыкты.

Урамда җәй – каникулның иң кызган чагы. Әлфис иртәнге аштан соң ук ишегалдына чыгып самокатына сикерде дә төшкә кадәр шунда йөрде. Әтисе белән сөйләшүне онытты, саклагыч җайланмаларын да кимәде.

Төштән соң Әлфис төп проспекттан яр буена алып баручы зур баскыч буйлап самокат белән төшәргә уйлады. Ул баскычтан кеше күп йөри. Алар арасында өлкәннәр, балалар белән әниләр, яшь парлар да бар. Тик бу Әлфисне туктатмады. Ул самокат белән баскычтан аска төшәргә уйлады, чираттагы баскычка сикергәндә, рульне үз кулыннан ычкындырды һәм самокат белән бергә аска тәгәрәде һәм җиргә барып төште. Бәхеткә каршы, Әлфис зыян күрмәде, әзрәк кенә куллары, аяклары сыдырылды. Менә самокат зыянны күбрәк күрде. Малайның бик ачуы килеп, ул самокатка китереп типте.

Самокат мондый мөнәсәбәткә түзә алмыйча телгә килде:

– Дустым Әлфис, ник син әтиең әйткән сүзләрне тыңламадың?

– Мин онытгым бит ул сүзләрне, нишләргә инде миңа хәзер?

– Кайгырма, дустым, икенче тапкыр саклангыч җайланмаларыңны кияргә онытма.

Өйгә кайткач, Әлфисне әти-әнисе сыдырылган кулларын аякларын яшел су белән дәваладылар, самокатны әтисе ремонтлады. Шуннан соң әти-әнисе Әлфисне әңгәмәгә чакырдылар:

– Әлфис, без сине самокатта йөрү кагыйдәләрен үтәргә кисәттек, нигә син саклангыч җайланмаларыңны кимәдең? – дип сорады әтисе.

– Гафу итегез мине, мин тизрәк самокатта йөрергә ашыктым, шуңа күрә кагыйдәләр һәм саклагыч җайланмалар турында оныттым, – диде малай.

– Улым, зинһар өчен игътибарлы бул! – диде әнисе.

Икенче көнне Әлфис ишегалдында күрше кызы Алинәне очратты. Әтиәнисе йөрү кагыйдәләрен үтәргә кисәткәнен тагын онытты.

– Алинә, сәлам! – диде Әлфис.

– Сәлам! – диде Алинә.

– Кара, минем нинди самокатым бар, – диде Әлфис.

– Әйе, матур, – диде Алинә.

– Әйдә, бергәләп самокатта йөрибез, – диде Әлфис.

– Юк, әйдә бергә туп белән уйныйбыз, – диде Алинә.

– Юк, мин самокатта йөрим, – диде Әлфис һәм китеп барды.

Шулвакыт Әлфиснең башына бер уй килде. Ул самокатны аяк белән этеп баруны бик авырга санады һәм, тизлекне арттырыр өчен, автомобильгә самокатны эләктереп куярга уйлады.

– Әлфис, алай ярамый, син юл йөрү кагыйдәләрен бозасың, – дип самокат телгә килде.

– Борчылма, әзрәк кенә йөрибез. Кара, әнә йөк автомобиле тора, әйдә, шуңа тагылабыз, – диде Әлфис.

Йөк автомобиле чыга башлагач, Әлфис арткы бамперга тагылды. Автомобиль ишегалдыннан чыкты һәм тизлекне арттыра башлады.

Малай бу хәлгә бик шатланды, зур тизлек белән самокатта җилдертү аңа бик ошады. Бу күренешкә самокат бик борчылды һәм тизрәк туктарга теләде. Кинәт туп һәм аның артыннан йөгерүче Алинә юлга килеп чыктылар. Йөк автомобилен йөртүче бәрелештән котылу өчен кискен рәвештә тормозга басты. Әлфис самокаты белән бергә автомобильгә бәрелеп алгы якка таба очты.

Юл хәрәкәтендә барлык транпорт төрләре дә туктап калдылар. Автомобиль йортучеләр малайга ярдәм итү өчен юлга чыктылар, кемдер ашыгыч ярдәм, кемдер ЮХИДИ хезмәткәрләрен чакырды. Әлфиснең хәле авыр иде. Ашыгыч ярдәм автомобиле килеп малайны хастаханәгә алып китте. ЮХИДИ хезмәтләре Алинәгә юлга чыгып йөгерүнең ярамавын аңлаттылар һәм ватык самокатны үзләре белән алып киттеләр.

Әлфис хастаханәдән терелеп чыкты. Өйдә малай һәм олылар арасында бик җитди сөйләшү булды.

– Улым, без сиңа самокат бүләк иттек. Бу синең хыялың иде. Юл йөрү кагыйдәләрен белергә кирәклеген турында сөйләдек, без сине кисәттек. Нигә син безне тыңламадың?– диде әтисе борчылып.

– Әти! Әни! Мин алай бүтән эшләмәм, сезне тыңлармын. Гафу итегез, мине, – диде Әлфис, уңайсызланып.

Сентябрь аенда мәктәпкә юл хәрәкәте инспекциясеннән Әлфиснең юл-транспорт һәлакәтенә эләгүе турында хат килде. Хатта малайның юл хәрәкәте кагыйдәләрен белмәве турында язылган һәм укытучыларның аның белән җитди сөйләшүләрен соралган. Шуңа күрә сыйныф җитәкчесе Әлфис белән әңгәмә үткәрде. Әлфис дөрес эшләмәвен, әти-әнисен тыңламавын, юлларда иминлек кагыйдәләрен бозуын аңлады. Нәтиҗәдә аның үз-үзен тотышы үзенә һәм башка кешеләргә дә зыян китерүенә төшенде. Әлфис барлык кагыйдәләрне дә белергә, аларны үтәргә һәм башка кешеләрне өйрәтергә теләде, шуңа күрә ул яшь хәрәкәт инспекторлары отрядына язылды. Самокат Әлфиснең бу теләген хуплады.



*Рәс. 13. III урын – Шәрәфетдинова А.Д., Кече яшьтәге мәктәп балалар өчен «Юллар безне алга дәшә» чәчмә әсәрләр номинациясе*

**Фикер алышу өчен сораулар:**

1) Малайның исеме ничек? Кызның исеме ничек?

2) Бер аяк белән этәсең,
Икенче аяк белән торасын.
Менә бик тиз барасың,
Очасың диярлек!
Нәрсә ул?

3) Әлфис нинди юл хәрәкәте кагыйдәләрен бозган?

4) Алинәгә туп артыннан автомобиль йөрү өлешенә йөгереп чыгарга ярый идеме?

5) Саклау элементларын ни өчен кияргә кирәк?

6) Сез юл хәрәкәтенең яшь инсекторлары турында беләсезме? Алар нәрсә белән шөгыльләнә?

7) Сез Әлфисне нинди итеп күз алдына китерәсез, рәсемен ясагыз.

# Кече яшьтәге мәктәп балалар өчен «Юллар безне алга дәшә» чәчмә әсәрләр номинациясе лауреатлары

## Беркеше

*Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы*
*«Биләркүл урта гомуми белем бирү мәктәбе»*
*муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең*
*11 нче сыйныф укучысы Гөлназ Рәдиф кызы Шәрипова (рәс. 14)*

Хөрмәтле иптәшләр, чираттагы җыелышыбызны башлыйбыз. Тынычлыкны саклавыгызны һәм бик тә игътибарлы булуыгызны үтенәм. Чөнки тарихта моңарчы беркайчан да, беркайда да, беркемдә дә булмаган очрак карала!

Бүгенге көн кадагына безгә, «Юллар безне алга дәшә» оешмасына, килеп төшкән бик тә үзенчәлекле хатны карау, тикшерү, фикер алышу, нәтиҗәләр чыгару куела. Безгә бу хатны шәхси транспорт чарасында йөрүче, шәһәр маршрут транспорт чараларын, светофор сигналы төсләрен санга сукмаучы язган. Менә болай дип яза ул һәм бездән булмастай адым ясауны сорый:

«Хөрмәтле «Юллар безне алга дәшә» оешмасы җитәкчелеге, мин шәһәр юлларында йөри белмим, светофор сигналы төсләрен аерып бетерә алмыйм, аларның нәрсә аңлатканы вакыт-вакыт истән чыга, миңа үз җаем белән йөрергә рөхсәт итегез әле һәм шулай ук башкаларга да. Кешеләр светофорның үз җайларына туры килә торган төсен үз автомобильләреннән кабызып үтә ала торган мөмкинлек эшләгез әле, җәяүлеләр кичүендә дә транспорт чараларына очкыч канатларын кабызып, җәяүлеләр өстеннән очып чыгып китәргә рөхсәт итегез әле. Сезнең уңай җавапка өметләнеп калам. Ихтирам белән, Беркеше».

– Иптәшләр, сез ничек карыйсыз бу хатка, мин шаккатып карыйм, мин аптыраошта. Шәһәребездә юл кагыйдәләрен бозып, юл һәлакәтләре ясаганчы, кешеләргә зыян салганчы безгә бу Беркешене тиз арада табып алырга кирәк, – диде оешма җитәкчесе, маңгайларын кульяулыгы белән сөртеп.

– Әйе, тизрәк тотарга бу Беркешене! – диделәр оешма хезмәткәрләре.

– Адресын күрсәткәнме соң ул? – дип сорады арадан берәү.

– Юк, күрсәтмәгән шул, – диде икенчесе.

– Ничек табабыз инде без ул Беркешене? – диде тагын бер хезмәткәр.

– Әнәәәә, таблога карагыз әле тизрәк, – дип кычкырып җибәрде җыелышны теркәп баручы.

Барысы да берьюлы стена тутырып эленеп торган зуууууур таблога карадылар. Анда берәү юл кагыйдәләрен үзенә җайлаштырып, башкаларга комачаулап йөри иде.

– Менә шул Беркеше түгелме соң инде бу?! Әйдәгез тизрәк кулга алыйк бу кешене, кире кайтара алмаслык хәл ясый күрмәсен юлларда, – диделәр хезмәткәрләр һәм ашыгыч рәвештә ЮХИДИ хезмәткәрләренә әмер биреп тотып та алып килделәр.

Беркеше оешмага килеп керү белән, стенадагы кагыйдәләр язылган, төрле төстәге, төрле билгеләр ясалган такталарга игътибар итте, авыз ачып, күзләрен тагы да зурайтып карап торды, нәрсәдер аңларга, истә калдырырга тырышты. Ләкин аны бу кагыйдәләр янында озак тотмадылар, оешма җитәкчесенә алып кереп киттеләр.

– Исәнмесез! − диде Беркеше, кабинетка килеп кергәч.

– Исәнмесез! – диде җитәкче. – Сезне бирегә ни өчен тотып китергәннәрен аңлыйсызмы? – дип дәвам итте сүзен.

– Әзрәк аңлыйм, күбрәк аңламыйм, − дип җавап бирде Беркеше.

– Нәрсә аңлыйсыз? – дип сорады җитәкче.

– Юл кагыйдәләрен бозып йөрим, ләкин кешеләргә әле зыян салганым юк, − диде Беркеше.

– Ә зыян салгач, нәрсә булачагын күзаллыйсызмы? – диде җитәкче.

– Юк, − диде Беркеше.

– Ә нәрсә аңламыйсыз? – дип сорады җитәкче?

– Юл кагыйдәләрен аңламыйм, шуңа үзем белгәнчә, үзем аңлаганча һәм үземә уңайлы итеп йөрим, − дип җавап кайтарды Беркеше.

– Күзалдыгызга китерегез әле, ә башкалар да нәкъ сезнеңчә йөрсә, нәрсә булачак? – дип катгый рәвештә сорады җитәкче.

– Аларга да минем кебек җиңел булачак,  миңа шулай җиңел бит йөрергә, − диде Беркеше.

– Сез әле күп әйберләрне аңламыйсыз икән, сезнең белән тизрәк эшләргә кирәк, − диде җитәкче.

– Мин каршы түгел, минем хатта язган үтенечләремне үтәсәгез, мин сезнең белән эшләргә риза, − диде Беркеше, җитәкченең ни әйтергә теләгәнен аңламыйча.

– Мин нәкъ сезнең хатта язган теләкләрегезнең дөрес түгеллеген һәм сезнең юлларда дөрес йөрмәвегезне аңлатырга телим, − диде җитәкче.

Беркеше уйга калды, аның тизрәк бу бүлмәдән чыгып китәсе, бинага кергәндә стенада эленеп торган язуларны укыйсы һәм рәсемнәрне карыйсы килеп китте.

– Әйдәгез, минем белән, − диде җитәкче һәм, Беркешене ияртеп, эш бүлмәсеннән чыкты.

Озын коридор буйлап барганда, Беркеше тагын стеналарга игътибар итте. Анда юлларда игътибарсыз җәяүлеләр, юл кагыйдәләрен сакламаучы җиңел автомобиль һәм йөк автомобиле йөртүчеләр, велосипед, мотоциклда баручылар аркасында килеп чыккан юл һәлакәтләре күрсәтелгән рәсемнәр эленгән иде. Кайберләре янында Беркеше озаклап торды, җентекләп карады, уйга батты, күзләрендә ниндидер курку чаткылары пәйда булды – җитәкче аны ашыктырмады, карарга, уйланырга вакыт бирде. Җитәкче бу коридорның Беркешегә ясаган тәэсирен шунда ук сизеп алды. Әкрен генә рәсемнәрне карый-карый баргач, алар зур бер залга килеп керделәр. Бу шәһәр макеты иде. Бөтен тыкрыклары, юллары, юл кисешкән урыннары, урнашкан йортлары, кибетләре, агачлары, куакларына, олы кешеләр утырып тора торган эскәмияләренә чаклы туры килеп торган шәһәр сыны иде ул.

Менә бу – безнең шәһәр, менә бу җирләрдә светофорлар урнашкан, менә бу сигнал шуны аңлата, менә бу шуның өчен кирәк, менә монысы – шуның өчен, – дип сөйләп җибәрде җитәкче кеше.

Беркеше авызын ачып, шаклар катып, җитәкчедән күзен дә алмый, бер макетка, бер җитәкчегә карый-карый, кызыклы мәгълүматны йотлыгып су эчкән кебек бер сулышта тыңлап торды. Җитәкче абый кызык итеп сөйли иде. Ул сөйләгәндә, Беркеше үзенең гаиләсен, әтисен, әнисен, энекәшләрен, туганнарын, дусларын күзалдына китерде. Юл кагыйдәләрен бозып йөргәндә, якын кешеләренә генә түгел, гомумән, башка таныш булмаган, таныш булган һәр кешегә үз куллары, үз теләге белән зыян ясарга мөмкинлеген, юл кагыйдәләренең, светофор сигнал төсенең барлык кешеләргә бер икәнен һәм ул кагыйдәләрне һичшиксез үтәргә, сакларга кирәклеген аңлады. Шушы көнгә кадәр күпме ялгышлар ясаганын, шул хаталарның зур зыян ясарга мөмкинлеген, ниндидер бер серле көч аркасында гына һәлакәт чыкмый калуы турында уйланды да, йөрәгенең авыртып куйганын тойды. Җитәкче абый кызыклы һәм үтемле итеп сөйли иде. Беркеше аның һәр сүзен йотып, аңлап, күңеленә язып, сеңдереп барды һәм күңел түрендә җиңеллек сизде.

– Иптәш җитәкче абый, гафу итегез, минем сезгә язган хатымның дөрес түгеллеген аңладым мин, юк итегез сез аны, кешегә күрсәтә күрмәгез, – диде.

– Беркеше, бу фикерең белән син мине куандырдың, димәк, син мин сөйләгәннәрне аңладың?! – дип сорады җитәкче.

– Әйе, аңладым, – диде Беркеше.

– Ярар, алайса, синең белемеңне тикшермичә, бу залдан чыгып булмый, – дип дәвам итте сүзен җитәкче. – Син сорауларга дөрес җавап бирсәң генә чыгып була, җавап бирмәсәң, әле тоткарланачакбыз шушында.

– Әйдәгез, тикшереп карыйк! – диде Беркеше, шатланып һәм үзендә ныклы ышаныч тоеп.

– Кызыл сигнал янганда, син нишләячәксең, Беркеше?

– Кызыл сигнал янганда, мин транспорт чарасы белән хәрәкәтне дәвам итәм, әгәр мин җәяүле икән, сабыр гына көтеп торам.

– Сары сигнал янганда нишлисең, Беркеше?

– Транспорт чараларны кабызырга әзерләнәм.

– Яшел сигнал янганда нишлисең, Беркеше?

– Яшел сигнал янганда, транспорт чараларны туктатып торам, җәяүлеләрнең юлны аркылы чыгып бетүен сабыр гына көтәм, аннан соң кызыл сигнал янгач кына, хәрәкәтемне дәвам итәм.

– Бу кагыйдәләр синең өчен генәме, Беркеше?

– Юк! Һичшиксез, бу кагыйдәләр минем өчен генә түгел! Бу кагыйдәләр барыбыз өчен дә!

– Бу кагыйдәләр ни өчен кирәк?

– Бу кагыйдәләр юлларда тәртип булсын өчен, кешеләр өйләренә, гаиләләренә, әти-әниләре, балалары, дуслары, туганнары янына исән-имин кайтып, барып җитсен өчен кирәк!

– Син үзеңнең хатаңны аңладыңмы?

– Аңладым! – диде Беркеше һәм җитәкче абыйның сузылган кулына җавап итеп кулын сузды. Бер-беренә хәерле, имин юллар теләп, кул кысканда, Беркешенең дөрес җавапларыннан зал ишеге ачылып китте. Беркеше белән җитәкче абый залдан чыктылар. Берсе эш бүлмәсенә, икенчесе урамга юнәлде.




*Рәс. 14. Шәрипова Г.Р., Кече яшьтәге мәктәп балалары өчен «Юллар безне алга дәшә» чәчмә әсәрләр номинациясе лауреаты*

Беркешенең шәхси юл транспортына утырып киткәнен, Җитәкче абый тәрәзәдән озак кына карап торды. Беркеше, башка кешеләр кебек үк, светофор сигналларын, юлчыларны, җәяүлеләрне ихтирам итеп, үзен шәһәр юлларында әдәпле һәм дөрес тотты. Шуның өчен аларның икесенең дә күңеле тыныч иде.

**Фикер алышу өчен сораулар:**

1) Ни өчен әсәр «Беркеше» дип атала?

2) Әсәрдә вакыйга кайда бара?

3) Әсәрдә вакыйга барган оешманың исеме ничек атала?

4) «Тарихта моңарчы беркайчан да, беркайда да, беркемдә дә булмаган очрак карала!» дигән сүзләрне ничек аңлыйсыз?

5) «Юллар безне алга дәшә» оешмасына нинди эчтәлекле хат килә?

6) Беркеше мондый хат язып дөрес эшләгәнме, сез ничек уйлыйсыз, аның хаты сезгә ошадымы, әллә ошамадымы?

7) Беркешене ни өчен кулга алдылар?

8) Беркеше, оешмага килеп кергәч, нигә авызын ачып, күзләрен тагын да зурайтып карап торды, ул нәрсә аңларга, истә калдырырга тырышты?

9) Беркешене кулга алып оешмага китергәч, ул «әзрәк аңлыйм, күбрәк аңламыйм», диде. Сез ничек уйлыйсыз, ул нигә алай җавап бирде?

10) Озын коридор турында нәрсә әйтә аласыз? Ул Беркешегә ничек тәэсир итте?

11) Җитәкче ни өчен Беркешене шәһәр макеты ясалган бүлмәгә алып керде?

12) Беркеше кайчан үз гаиләсен һәм туганнарын исенә төшерде?

13) Беркешенең кайчан йөрәге авыртты?

14) Шәһәр макеты урнашкан зал ишеге кайчан ачыла?

15) Ни өчен әсәр ахырында Җитәкче абый белән Беркешенең күңеле тыныч иде?

## Тапкыр светофор һәм ике сәяхәтче малайның мажаралары

*Татарстан Республикасы буенча Россия Федерациясе*
*Пенсия фонды дәүләт учреждениесенең иминиятләштерелгән затларның*
*пенсия хокукларын бәяләү төркеме өлкән белгече*
*Айгөл Рөстәм кызы Мортазина (рәс. 15)*

Кичә Марсельгә 10 яшь тулды. Бүген иртән тору белән ул көзге янына килеп басты. Аннан Марсельгә акыл утырткан зур егет карап торган кебек то-

елды. Шулчак телефон шалтыравы малайның уй-фикерләрен өзде. Телефон экранында дусты Әмирдән смс килгәне күренеп тора иде. Әмир Марсельнең туган көненә бүләк итеп «маҗаралы сәяхәт» оештырырга вәгъдә биргән. Смста нәкъ шигырьдәгечә «Юллар безне алга, алга дәшә!» дип язылган. Менә, сиңа мә! Бу җөмлә астында әллә нинди могҗизаларны күз алдында тотарга мөмкин ич! Шунда ук аның фантазиясе миллион сценарий уйлап чыгарды. Инде ул күңеле белән олы юллар гизеп, әллә кайларда сәяхәттә йөргәндә генә ишек шакыдылар. Ә ишек артында, еш-еш сулап, аркасына олы рюкзак аскан Әмир басып тора иде.

– Дустым, җыен тизрәк, киттек сәяхәткә! – диде, дулкынлануын яшермичә Әмир.

– Тукта әле, кая ашыгабыз? Әнидән рөхсәт тә сорарга җитешмәдем, – диде Марсель.

– Тизрәк, дим мин сиңа, телефоннан шалтыратып хәбәр итәрсең, вакытны сузма, – диде Әмир катгый гына.

Марсельнең ашыгуы чамасыз булды: өйдән чыгып киткәндә, телефонының зарядкада калганын да абайламады.

...Юл чатындагы светофор – «Ялкын»ның бүген нигәдер кәефе төшенке иде. Ул инде бик күптәннән мондагы юл хәрәкәтен көйләп торса да, аның сигналларын игътибарсыз калдыручылар җитәрлек шул. Бүген исә андый очраклар аеруча күп булды. Шулвакыт «Ялкын» еракан үзенең иң яраткан җәяүлеләрен күреп алды. Алар – Марсель белән Әмир иде. Малайлар беркайчан да, бервакытта да юл кагыйдәсен бозмадылар. Светофорга «Ялкын» исемен дә алар бирделәр. Чөнки инде күп еллар үз эшен төгәл башкара ул, ә Әмир белән Марсель юлны аркылы чыкканда, утларын көчәйтебрәк яктырта иде.

Малайлар юл чатына килеп житкәндә, «Ялкын» жәяүлеләр өчен «аркылы чыгарга рөхсәт бетә»дигән сары сигналны кушты.

– Чапма инде, Әмир. Әнә, «Ялкын» хәзер кызыл сигналын кушачак, көтеп торыйк, – дип, дустын туктатмакчы булды Марсель.

– Җитешәбез, тизрәк атласаң, – дип, Әмир, кулыннан йолкып диярлек, юлга алып чыкты дустын. Сулны, уңны да карап тормыйча, каршы якка йөгерделәр алар.

«Ялкын» ни эшләргә дә белмәде, юлдагы транспорт чаралары инде светофорның яшел сигналлын көтеп арып, сигналларын кычкырттылар. Кайберәүләре хәтта кузгала да башладылар. Светофор, кагыйдәсен бозып, сары сигналны кызылга алыштырмый торды. Малайлар юлны аркылы чыгарга җитештеләр.

– Чүттән генә исән калдык, Әмир! Ни эшлисең син?! – дип ачу белән әйтте Марсель.

– Мин бит сиңа маҗаралы сәяхәт була дидем, – дип бары тик күлде генә Әмир. – Безнең «Ялкын» – молодец! Аның безгә ярдәмгә киләсен мин белдем!

Малайлар юлларын дәвам иттеләр. «Ялкын» сөйләшә алса, Әмирне бик орышыр иде, әлбәттә. Светофорның сигнал пыялалары парланып чыкты хәтта. Аның чаткысы бик җаваплы, күп куркыныч һәлакәтләр күрде ул. Инде үзенең яраткан җәяүлеләре исән-имин юлны аркылы чыккач, җиңел сулап куйды «Ялкын».

Малайлар юлларын дәвам иттеләр. Әмирнең планы буенча алар 35 нче номерлы автобуска утырырга тиешләр иде. Тукталышка килеп җиткәндә, Марсельнең әнисенә шалтыратмаганы кылт итеп исенә төште. Ул кесәләрен капшады, ләкин телефонын таба алмады. Шунда малай аның өйдә калганын аңлады.

– Әмир, минем телефон өйдә калган, ахры. Синекеннән генә шалтыратыйм әле әнигә, – дип, дустына дәште.

– Әнә, безнең автобус килә. Әйдә утырыйк, аннан шалтыратырсың, – диде Әмир.

Малайлар автобуска кереп утырдылар. Ни гаҗәп, кеше бик күп тугел иде. Әмир рюкзагыннан телефонын табып, дустына бирде. Марсель әнисенә әллә ничә тапкыр җыйды, ләкин әнисе җавап бирмәде. Кызганычка каршы, әтисенең телефон номерын яттан белми иде.

35 нче автобус шәһәр янындагы Кырынтау авылына тикле бара. Шәһәрнең соңгы тукталышында да чыкмагач, Марсель Әмирдән:

– Кайда барабыз соң без? Шәһәрдән чыгып китәбезмени? – дип, шикләнеп сорады.

– Әлбәттә! – диде Әмир, – Без бит сәяхәткә чыктык!

Моңынчы Марсельгә бу маҗара кызык тоелса, хәзер малайның күңеленә шик төште. Әнисенә әйтмичә, болай еракка бер үзенең киткәне юк иде аның.

Менә автобус соңгы тукталышка килеп җитте. Марсельгә әнисе һәрвакыт автобусны арт ягыннан урап узарга куша иде. Малай шуны истә тотып автобустан чыккач, уңга борылды да тукталышка таба китте. Кинәт автобус сигналын кычкыртып җибәрде. Марсель кискен көчле тавыштан сискәнеп китте. Артына борылып караса, Әмир автобусның алдыннан үтеп бара икән. Инде кузгала башлаган автобус кинәт туктады. Шулчак ишектә йөртүче күренде:

– Ни эшлисең син, әй, малай! – дип, мөрәҗәгать итте ул Әмиргә. – Син әллә юлда йөрү кагыйдәләрен белмисең? Мин дә синең кебек игътибарсыз булсам, икебез дә харап була идек бит! Исеңдә калдыр: автобусның, троллейбусның, трамвайның артыннан һәм алдыннан урап узарга ярамый!

Әмир башын аска иеп тора бирде. Аңа бик уңайсыз булды.

Автобус кузгалгач, малайлар авыл читендәге яланга юл тоттылар. Нинди генә гаҗәеп матур чәчәкләр, хуш исле үләннәр юк иде анда! Кечкенә кояшлар төсле янып утырган тузганаклар дисеңме, бөтен һаваны үзенең исе белән уратып алган мәтрүшкәләр, серле кыңгыраулар дисеңме – барысы да бар анда. Җәйге кояшның җылы нурлары талгын җилгә уралып, ялandагы чәчәкләрнең өсләреннән сыйпап-сыйпап уздылар.

Әмир авыр рюкзагын салды да, бавыннан тартып ачып җибәрде. Аннан ашъяулык чыгарып җиргә җәйде. Ашъяулык өстенә бер-бер артлы чәй белән термос, җиләк-җимеш, бутерброд, яшелчә, чәй тәм-томнары урнашты. Инде яшь сәяхәтчеләрнең тамаклары ачкан иде. Бераз капкалап алгач, малайлар футбол уйнарга керештеләр. Әмирнең рюкзагының төбенә хәтта туп та сыйган иде.

Уйнап, ял итеп, кызыклы хикәяләр сөйләп, вакыт бик тиз узып китте. Марсель тагын әнисенә шалтыратып карамакчы булды, ләкин телефон челтәре авылда тотмаганлыгы ачыкланды.

– Әмир, бик зур рәхмәт сиңа! Миңа синең бүләгең бик ошады! – диде Марсель. – Инде кояш баю ягына авышты, кузгалыйк.

– Дөрес әйтәсең, – диде Әмир, дустын хуплап. Малайлар әйберләрен җыйдылар да юлга кузгалдылар. Тукталышта шактый озак торырга туры килде аларга. Тик автобус гына күренмәде. Малайлар соңга калуларын аңладылар. Әмирнең телефоны да сүнгән иде. «Сәяхәтчеләр»не курку хисе биләп алды. Әмма җәяүләп юлга кузгалырга батырчылык итмәделәр.

...Инде Марсельнең әнисе эштән кайткан иде. Улының өйдә булмавы аны борчуга салды. Телефонын да алмаган, җитмәсә! Иртәнге якта әни кешегә ниндидер таныш түгел номердан шалтыраткан булганнар. Әмма ул аны алырга җитешмәде, чөнки җыелышта булды. Ә инде үзе шалтыратканда, оператор абонент белән тоташтыруның мөмкин түгеллеген генә кабатлап торды. Күңеленә шом төште әнисенең, ул тиз генә җыенды да өйдән чыгып китте.

Ире күреп алып, аның каршына таба атлады:

– Әтисе, Марсель өйдә юк, күңелем тыныч түгел. Эзләргә кирәк, – диде.

– Әйдә, Әмирләргә кереп карыйк, анда түгел микән? – диде, әти кеше. Алар өй янына килеп җиткәндә, Әмирнең әнисе дә улын эзләп чыгып килә иде.

Ике үсмернең дә әти-әниләре балалары өчен бик курыктылар, әллә нинди шомлы уйлар килде алар башына. Әрле-бирле чаптылар алар. Шулчак Марсельнең әтисе «Ялкын »ның мәзәк итеп биргән сигналларына күз салды.

– Карагыз әле, безнең ничә еллар бер ялгышлык та җибәрми эшләгән светофорыбыз бүген гадәти булмаган сигналлар бирә, – диде ул, светофорның бер туктаусыз әле сары, әле яшел сигналлары яктыртуына карап.

Бичара «Ялкын», хәлнең нәрсәдә икәнен аңлап, малайларның әти-әнисенә үзенчә ярдәм итәргә тырышты. Бертуктаусыз яшел сигнал белән өч, сары сигнал белән биш тапкыр сигнал бирде. Әмир белән Марсельнең нинди номерлы автобуска утырып киткәннәрен күргән иде шул ул.

– Әгәр дә ул безгә берәр нәрсә әйтергә теләсә? Малайлар бит аның белән чын кешедәй сөйләштеләр, хәтта исемен дә «Ялкын» дип үзләре бирделәр, – диде Әмирнең әнисе. Марсельнең әтисе уйланып торды да, светофор кырына килеп:

– «Ялкын», хәзер бераз туктап, яңадан хәбәреңне кабатла әле? – дип, мөрәҗәгать итте. Шул чак «Ялкын» кызыл сигналны яктыртып алды да, яңадан өч тапкыр яшел сигнал һәм биш тапкыр сары сигнал бирде.

– Өч һәм биш… нәрсә икән ул, – дип, Әмирнең әнисе уйланып торганда, Марсельның әнисе:

– Бәлки ул утыз биш санын аңлатадыр! – диде.

– Утыз бишенче автобус диясе килә аның! – дип, светофорның хәбәренә төшенде Марсельның әтисе. Шулчак аны дөрес аңлауларын күрсәтеп, «Ялкын» гадәттәгечә эшли башлады.

– 35 нче автобус авылга тикле бара, – дип ачыклады Әмирнең әнисе – өйдә Әмирнең рюкзагы да, термос та юк. Мөгаен, малайлар пикник оештырырга булганнардыр.

– Утырыгыз автомобильгә! Киттек! – диде Марсельнең әтисе. Алар өчәүләп юлга кузгалдылар. 35 нче автобусның маршруты буйлап малайларны эзләргә киттеләр.

Ә бу чакта Әмир белән Марсель сүз дә алышмыйча тукталышта утыра бирделәр. Инде караңгы төшкән иде. Малайлар яныннан бер кеше дә, хәтта бер транспорт чарасы да узмады. Марсельнең күзләренә яшь тулган иде. Бер заман ерактан автомобильнең утлары күренә башлады.

– Болай төне буеп утырып булмый инде монда, – дип Әмир автомобильне туктатырга теләп юлга чыкты.

Марсельнең әтисе бик дулкынлана иде, газ педалена артык басуын үзе дә абайламый калды. Шулчак юлга нәрсәдер атылып чыкты. Көч хәл белән автомобильне туктатырга җитеште әтисе. Әнисе йөгереп чыкты, юлда аның улы Әмир басып тора иде.

– Балам! – дип, кочаклап алды ул малаен – бик куркыттың бит син мине!

– Әниләрегезгә әйтмичә, рөхсәт алмыйча, ни эшләп йөрисез сез?! – дип, малайларны орышырга кереште Марсельнең әтисе. – Җитмәсә, караңгы вакытта юлга атылып чыгасыз. Фликерлар да бар бит! Аларны кулланырга кирәк!

– Гафу итегез безне, без зур ялгышлык эшләдек, – дияргә генә батырчылык итте Марсель. Әти-әнисе каршында бик оят иде аңа.

Өйгә кайтканда, Марсельнең әнисе малайларга «Ялкын»ның аларны табарга ничек ярдәм иткәнен сөйләп бирде. Марсель белән Әмир светофорның могҗизалы булуы ачыклануга сөенделәр, ләкин алар гаҗәпсенмәделәр, чөнки «Ялкын»ның гади светофор гына түгеллеген дуслар инде күптән беләләр иде. Марсель Әмиргә дәшеп:

– Әмир, икенче юлы маҗаралы сәяхәткә барасың килсә, юл кагыйдәләрен әйбәтләп өйрән! – диде.

– Әйе, Марсель. Мин бүген юлда йөру кагыйдәләренең никадәр мөһим икәнлекләрен аңладым! Аларны бозу зур фаҗигага китерергә мөмкин! – дип җавап кайтарды Әмир.



*Рәс. 15. Мортазина А.Р., Кече яшьтәге мәктәп балалар өчен «Юллар безне алга дәшә» чәчмә әсәрләр номинациясе лауреаты*

**Фикер алышу өчен сораулар:**

1) Әкиятнең төп геройларын атагыз.

2) Әмир Марсельнең туган көненә нәрсә бүләк итте?

3) Малайлар светофорга ни өчен «Ялкын» дип исем бирделәр?

4) Әкияттә нинди юл йөрү кагыйдәләре тасвирланган? Сез тагын нинди кагыйдәләр беләсез?

5) «Ялкынның» могҗизалы булуы ничек ачыкланды?

6) Маҗаралы сәяхәт малайларны нәрсәгә өйрәтте?

7) Сез Марсельне һәм Әмирне нинди итеп күз алдына китерәсез, рәсемен ясагыз.

# 3. МӘКТӘПКӘЧӘ ЯШЬТӘГЕ БАЛАЛАР ӨЧЕН «МОГҖИЗАЛЫ ЮЛЛАР» ШИГЪРИЯТ НОМИНАЦИЯСЕ

## I урын

### Бер, ике, өч...

*Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы*
*«8 нче номерлы «Виктория» балалар бакчасы»*
*мәктәпкәчә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесенең*
*кече тәрбиячесе Алсу Фәрит кызы Сафина (рәс. 16)*

Бер, ике, өч...
Өч яшьлек Дилә
Әнисе белән
Бакчага килә.

Ул гел ашыга,
«Әни, ди, тизрәк!»
Үз бакчасын ул
Ярата бигрәк.

«Көтә, ди, безне
Анда апабыз.
Без акрын барсак,
Соңга калабыз».

Ә юл чатында
Светофор тора.
Кызыл сигналда
«Чыкма, ди, юлга!»

Нәни Диләгә
Әйтә әнисе:
«Белергә кирәк
Сиңа өч сигнал!

Бер, ике, өч,
Кызыл, сары, яшел.
Юлдан йөрергә
Кирәк бит дөрес!

Әнә светофор,
Сигналы – «кызыл».
«Кызыл сигнал»да
«Ярамый, кызым!
Чыгарбыз юлдан
«Яшел» янганда».

Әнисе шулай
Нәни Диләгә
Юл кагыйдәсен
Көн дә өйрәтә.

Ашыкмый хәзер
Өч яшьлек Диләә.
Юл кагыйдәсен
Ул яхшы белә.

## Өч сигналлы дустыбыз

Юлдан үткән чагында
Ул безгә сәлам бирә.
Аның төсле сигналы бар,
Нәрсә соң ул, кем белә?

Әйе, әйе, светофор ул,
Ул – безнең юл дустыбыз.
Юлда барган хәрәкәтне
Тәртиптә тотучыбыз.

Өч сигналы алмаш-тилмәш
Бер кабына, бер сүнә.
Светофорның һәр сигнал төсенә
Бөтен кеше буйсына.

Әнә кызыл сигнал яна,
«Ярамый! – ди, – кузгалма!»
Юлдан чыгу бик куркыныч,
Автомобиль узганда.

Сары сигнал әйтә безгә:
«Сабыр бул, – ди, – көт бераз».
Юл аша чыгарга ярый,
Яшел сигнал кабынгач.
Көне-төне сакта тора,
Йокламый ул, гел эштә.
Юл кагыйдәсен белергә
Тиешбез һәммәбез дә!

## Юлда булсаң, бул уяу

Автомобильгә утыргач,
Иң беренче чиратта
Эләктер саклык каешын,
Аннары кузгал юлга.

Юлда булсаң, уяу бул син,
Йөре сакланып кына.
Ашыкма син, тәртипле бул,
Тизлегеңне арттырма.

Әнә кара, күпме билге
Куелган юл чатында.
Һәр билге нидер аңлата
Ялгышмас өчен юлда.

Кайсы билге рөхсәт итә,
Кайсы тыя, кисәтә.
Уңга, я сулга барырга
Юнәлешне күрсәтә.

Тукта! Көт син! Юлдан чыгар
Олыны һәм кечене,
Әнә кара, билге тора –
«Җәяүлеләр кичүе».

Юл билгеләрен белмәсәң,
Юлда йөрү куркыныч.
Һәрвакытта, һәркайда да
Игътибарлы булыгыз!




*Рәс. 16. I урын – Сафина А.Ф., Мәктәпкәчә яшьтәге балалар өчен «Могҗизалы юллар» шигърият номинациясе*

**Фикер алышу өчен сораулар:**

1) Бу шигырь сезгә ошадымы? Ни өчен?
2) Әти-әниләрегез гаиләдә сезнең белән бу темага сөйләшәләрме?
3) Үзегез өчен нинди яңа информация алдыгыз?

## II урын

## Коңгыз маҗаралары әкияте

*Казан шәһәре Совет районының*
*«Катнаш төрдәге 177 нче номерлы балалар бакчасы»*
*муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесенең*
*тәрбиячеләре Гүзәл Фәнил кызы Мөхәммәтгәрәева,*
*Фиалка Минсәгыйт кызы Сәляхова (рәс. 17)*

Борын-борын заманда,
Ерак түгел,  Казанда
Яшәгән ди, бер йолдыз –
«Йолдыз» исемле коңгыз.

Коңгыз бик чая булган,
Тыңгысыз, шаян булган,
Беркемне тыңламаган,
Җемелдәгән, балкыган.

Ә көндезен бу коңгыз
Футбол тибеп уйнаган.
Юлдагы хәрәкәтне
Игътибарга куймаган.

Шулай бер көн, кич белән,
Ул балкудан туктаган.
Шуңарга гаҗәпләнеп,
Куркуыннан елаган.

Шулвакыт ул еракта
Бер ут күреп алган.
«Ни булса, булыр», – диеп,
Утка таба юнәлгән.

Килеп җитсә, ни күрсен –
Бу бер иске йорт икән.
«Карт коңгыз өе» диеп,
Ишегенә эленгән.




*Рәс. 17. II урын – Сәляхова Ф.М., Мәктәпкәчә яшьтәге балалар өчен «Могҗизалы юллар» шигърият номинациясе*

Бу коңгыз – күрәзәче,
Тылсымчы бер карт икән.
Йөреше көчкә-көчкә,
Ә сакалы – җиргә тигән.

Яшь коңгыз тылсымчыга
Үз зарларын сөйләгән.
Карт коңгыз китабыннан
Сәбәпләрен эзләгән.

«Кара әле, монда улым!» –
Дип башлаган ул сүзен.
«Балкымавыңның сәбәбен,
Бәлки, табарсың үзең.

Юл кагыйдәләрен дә
Гел үтәмисең икән!
Олыларны тыңламасаң,
Син балкымассың бүтән!»

«Аңладым мин барын да!» – дип,
Кычкырган, ди, яшь коңгыз.
«Үтәрмен кагыйдәләрне
Һәрвакытта, һичшиксез!»

И гаҗәп хәл, шулвакыт
Кабат кабынган коңгыз!
Тирә-якны ялт иттереп,
Яктылык чәчкән Йолдыз!

**Фикер алышу өчен сораулар:**
1) Әкияттә кайсы шәһәр тасвирланган?
2) Коңгыз нинди булган?
3) Ни өчен коңгыз балкудан туктаган?
4) Коңгыз еракта нәрсә күргән?
5) Карт коңгыз кем булган?
6) Яшь коңгыз тылсымчыга нәрсә сөйләгән?
7) Бу әкиятне тыңлагач, нинди фикергә килдең?
8) Сез Коңгызны нинди итеп күз алдына китерәсез, рәсемен ясагыз.

## III урын

## Беркайчан да онытма

*«Лениногорск нефть техникумы»*
*дәүләт автоном профессиональ белем бирү учреждениесе*
*студенты Айгиз Фәрид улы Мөхәммәтҗанов (рәс. 18)*

Транспорт чаралары
Юллардан тыз-быз уза:
Зурысы йөк автомобиле,
Кечесе – җиңел була.

Автомобиль йөк төягән:
Кирпеч, такта, таш, утын,
Шуңа күрә исеме аның
Йөк автомобиле, дустым.

Җиңел, диләр, син утырып
Бакчага йөри торган
Бәләкәй автомобильләрне.
Бармы соң рулен борган?

Кешеләр юлга чыкмый,
Тротуардан гына йөри.
Светофор тора чатта,
Ул хәрәкәтне көйли.

Яшел сигнал рөхсәт бирә
Кичү аша узарга.
Сары сигнал, игътибар, ди,
Кызыл сигнал: туктарга!

Автобус, трамвай, троллейбус
Пассажирларны төйи.
Бу транспорт чаралары
Маршрут буенча йөри.

Йөртүче булмаса, боларның
Берсе дә йөрмәс иде.
Ерак арага беркемнең
Барасы килмәс иде.

Транспорт чаралары
Һәркемгә дә бик җайлы.
Барасы җиргә баруны
Итә алар уңайлы.

Юлда йөрү кагыйдәләрен
Белү кирәк һәркемгә.
Җәяүлене, йөртүчене
Алар хәвефсез итә.

Җәяүледән йөртүчегә
Үсеп җитәргә шуңа,
Кагыйдәләрне өйрән дә
Беркайчан да онытма!



*Рәс. 18. III урын – Мөхәммәтҗанов А.Ф., Мәктәпкәчә яшьтәге балалар өчен «Могҗизалы юллар» шигърият номинациясе*

**Фикер алышу өчен сораулар:**

1) Нинди транспорт чарасы йөк автомобиле дип атала?

2) Юлларда тагын нинди транспорт чаралары йөри? Алар ни өчен шулай атала?

3) Юлларда җәяүлеләр йөри торган урын ничек атала?

4) Автобус, трамвай, троллейбус кайларда йөри?

5) Йөртүче кем ул? Ул җәяүледән нәрсәсе белән аерыла?

## Мәктәпкәчә яшьтәге балалар өчен «Могҗизалы юллар» шигърият номинациясе лауреатлары

### Сак булыгыз юлларда!

*А. Н. Туполев исемендәге Казан милли тикшеренү техник университеты – КАИ студенты Ильяс Илгиз улы Вәлиуллин (рәс. 19)*

Җәйге матур бер көндә,
Саф һавалы иртәдә
Ике куян баласы
Юл тоттылар шәһәргә.

Бара торгач, ардылар,
Аяклары талдылар.
Әниләрен сагынып,
Бераз елап алдылар.

Берсе әйтә: «Кайтыйк», – ди,
Икенчесе: «Барыйк!» – ди.
«Ярты юлдан борылу –
Егет эше түгел», – ди.

Хәлдән тайган дускайлар
Шәһәрдә адаштылар.
Елый-елый чабалар,
Кайтырга юл тапмыйлар.

Автомобильләр бик күп уза,
Юлларда тузан туза.
Бер тәгәрмәч куянның
Аягын таптап уза.

Елый куян баласы,
Белми кая барасы.
Ярый әле аларны
Куып җитә анасы.

Балалар үкенделәр
Һәм гафу үтенделәр.
Бүтән өйдән китмәскә
Вәгъдәләрен бирделәр.

Әнкә куян акыллы,
Өйрәтте балаларны:
Сак булыгыз юлларда,
Шәһәрдә һәм авылда,
Перронда, тукталышта.
Сабыйлар һәм өлкәннәр,
Җәяүле, йөртүче.
Юл йөрү кагыйдәсен
Үтәгез һәммәгез дә!




*Рәс. 19. Вәлиуллин И.И., Мәктәпкәчә яшьтәге балалар өчен «Могҗизалы юллар» шигърият номинациясе лауреаты*

**Фикер алышу өчен сораулар:**

1) Шигырь сезгә ошадымы? Ни өчен? Шигырьдә сүз нәрсә турында бара?
2) Куяннар үзләре генә шәһәргә китеп дөрес эшлиләрме?
3) Ни өчен куян балалары авыр хәлдә калалар?
4) Әнкә куян турында сөйләгез. Ул нинди?

5) «Ярты юлдан борылу – егет эше түгел» дигән җөмләне ничек аңлыйсыз? Шигырьнең эчтәлегенә туры киләме?

6) Ни өчен юл йөрү кагыйдәләрен үтәргә кирәк?

7) Сез Куяннарны нинди итеп күз алдына китерәсез, рәсемен ясагыз.

## Юл кагыйдәләрен истә тот!

*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының «37нче балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе тәрбиячесе Эльвира Фәрит кызы Ветошкина (рәс. 20)*

Кечкенә малай беркөнне
Әтисе янына килде.
Күзләренә карады да,
Гади бер сорау бирде:

– Аңлат әле, нигә кирәк
Юл кагыйдәсен белү?
Ишеттем, хәтта шунда дип
Озак яшәүнең сере?

– Менә бусы– светофор
Һәр кешене күзәтә.
Юл аша дөрес чыгарга
Ул һәркемне өйрәтә.

Юлда йөрсәң, бул өлгер,
Игътибарлы бул син гел.
Светофорның һәр сигналы
Нәрсә аңлатканын бел.

Светофорның сигналлары
Яшел, сары һәм кызыл.
Безгә исән йөрергә
Булыша ул көнозын.

Яшел сигнал аңлата:
Кешеләргә юл ачык.
Ашыкмыйча гына син
Юллар аша, улым, чык.

Сигналларның сарысы
Уртасында тора.
Игътибарлы булырга
Өйрәтә ул барсын да.

Әгәр янса кызыл сигнал:
Барма, тукта шунда ук.
Алга барыр өчен безгә,
Димәк, әле юл ябык.
Светофорның һәр әмерен
Тиешенчә үтәсәң,
Озак яшәрсең,улым, син,
Имгәнүләр күрмәссең.

Җәяүлеләр кичүеннән
Юл аша син чык һәрчак.
Күзләрең гел юлда булсын,
Ашыкма син, бул гел сак.




*Рәс. 14. Ветошкина Э.Ф., Мәктәпкәчә яшьтәге балалар өчен «Могҗизалы юллар» шигърият номинациясе лауреаты*

Кагыйдәләрне белсәң дә,
Барысыннан да бигрәк,
Юл аша чыкканда,
Кабаланмаска кирәк.

Юл кагыйдәләрен һәркем
Тиеш төгәл үтәргә.
Шулвакытта гына сиңа
Тыныч булыр яшәргә.

– Рәхмәт, әти, сүзләреңне
Чыгармам мин исемнән.
Юл кагыйдәләрен бозмаска
Сүз бирәмен бүгеннән.

**Фикер алышу өчен сораулар:**

1) Бу шигырь сезгә ошадымы? Ни өчен?
2) Әти-әниләрегез гаиләдә сезнең белән бу темага сөйләшәләрме?
3) Үзегез өчен нинди яңа информация алдыгыз?

# 4. КЕЧЕ ЯШЬТӘГЕ МӘКТӘП БАЛАЛАРЫ ӨЧЕН «ИМИН БУЛА КҮРСЕН ЮЛЛАР» ШИГЪРИЯТ НОМИНАЦИЯСЕ

## I урын

### Төнге сабак

*Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының «В. Г. Тимирясов исемендәге 1нче Аксубай урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең 9 нчы сыйныф укучысы Айзилә Рафик кызы Галиева (рәс. 21)*

Куян, Керпе, Тиен, Төлке
Сәяхәткә киткәннәр.
Барып җиткәч кенә, алар
Өйгә хәбәр иткәннәр.

Ял иткәннәр аланнарда,
Болында уйнаганнар.
Күбәләкләр, кошлар белән
Сөйләшеп туймаганнар.

Чишмәләрне, елгаларны,
Зур тауларны кичкәннәр.
Тәмле сыйлар авыз итеп,
Шифалы су эчкәннәр.

Кайтырга да вакыт җиткән:
Иңеп килә караңгы.
Өйгә дәшеп ишетелә,
Тавыш әллә каяндыр.

Караңгыны күреп тәмам,
Дуслар куркып калганнар.
Юлдан барган бу дүрт дусны
Ярый күреп алганнар!

Яктылык кайтаргычлары
Юк икән өсләрендә.
Йөртүчеләр караңгыда
Аермый төсләрне дә!

Күз күреме начар була
Томанда, кичен, төнлә.
Бел, дус, яктылык кайтаргыч
Тасма ябыша киемгә.

Автомобильнең фарасы
Юл яктыртырга җитми!
Ярый әле бу дүрт дусны
Йөртүче харап итми!!!

Төлкенең койрыгы озын,
Ләкин күренми икән.
Юлда кара ноклалар бар:
Керпеме, ташмы икән?!

Тиеннең койрыгы озын,
Колаклары – куянның.
Йөртүченең күзе үткен,
Күңеле һәрчак уяумы?!

Сигез күз ялтырый юлда,
Күктәге йолдыз сыман.
Курыкканга куш күренә:
Алда гел тоташ томан.

Зур тизлекле автомобиль
Вәкаләтен арттырган.
Төнлә йөргән юлчыларның
Чәчен үрә бастырган.

Яктылык кайтаргычлары
Булмаганны күрмәгән.
Ярый, тизлеген киметкән –
Өсләренә менмәгән!!!

Сибелгәннәр тирә-якка
Керпе, Тиен, Куяннар.
Исән-сау калганнарына
Шөкер итеп куйганнар!

Шушы хәлләр сабак бирә
Төнге юлда йөрмәскә!
Гомерләрне саклый торган
Кагыйдәне белмәскә?!

Кайтаргычның ниндие юк:
Эмблема, брелок,тамга.
Шуның берсен алып так та,
Яшь дустым, алга атла!

Юллар имин булсын өчен,
Кагыйдәләрне бел, дус.
Иң тәртипле җәяүле бул,
Иң акыллы булып үс!

Юл йөрү фәне катлаулы,
Үзләштер аны яхшы!
Имин хәрәкәтләр сезгә,
Уңышлы юллар язсын!

Юл чатында игътибар ит
Светофорның күзенә.
Кайтаргычлар тагып йөрсәң,
Имин була үзеңә!

Модалы колакчаларын
Куянкай юлда кими.
Тиен, Төлке, Керпе дус та
Ут кайтаргычсыз йөрми.

Хәлне дуслар тиз аңлаган:
Кайтаргычлар алганнар.
Кием, букчага тагыгыз
Сез дә, газиз балалар!



*Рәс. 15. I урын – Галиева А.Р., Кече яшьтәге мәктәп балалары өчен «Имин була күрсен юллар» шигърият номинациясе*

**Фикер алышу өчен сораулар:**

1) Куян, Керпе,Тиен, Төлке кая киткәннәр?

2) Алар аланга китүләре турында өлкәннәргә кайчан хәбәр иткәннәр? Алар дөрес эшләгәнме?

3) Алар кайларда ял иткәннәр?

4) Дуслар нәрсәдән куркып калганнар?

5) Ни өчен дуслар караңгыдан курыкканнар?

6) Ни өчен юлда төнлә йөрү куркыныч?

7) Төнлә юллар имин булсын өчен нинди чара күрергә кирәк?

8) Фликерлар төнге юлларда гомерләрне саклап кала аламы? Сез ничек уйлыйсыз?

9) Юллар имин булсын өчен нәрсәне белергә кирәк?

10) Юл чатында нәрсә басып тора?

11) Светофор ни өчен кирәк?

12) Колакчаларны киеп юлда йөрергә ярыймы? Юл аша чыкканда, колакчаларны кияргә ярыймы? Ни өчен?

13) Ә Сез, яшь дус, юл йөрү кагыйдәләрен беләсеңме?

14) Сез Куянны, Керпене, Тиенне, Төлкене нинди итеп күз алдына китерәсез, рәсемен ясагыз.

## II урын

## Җәяүле идем мин дә

*Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Шәле «Тургай» балалар бакчасы муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе тәрбиячесе Лилия Габделхак кызы Газимова (рәс. 22)*

Минем исемем Аяз,
Сөйлим сезгә бер көнне:
Ничек итеп мәктәпкә
Әнием илтте мине.

Шулай туры килде менә
Җәяү барырга безгә.
Җиңел автомобильдә
Әти китте эшенә.

Үзе бер кызык икән
Бу юлларда йөрүе.
Яңадан кабатладым
Өйрәнгән кагыйдәне.

Менә җәяү чыгып киттек,
Без бүген «җәяүлеләр».
Димәк, туры килә безгә
Искәртү кагыйдәләр.

«Җәяүлеләр кичүенә»
Барып җиттек, ниһаять.
Ник берәү дә кузгалмый соң,
Торалар алга карап?

Йөк автомобильләре уза,
Күзләрен кысып миңа.
Әйтерсең лә әйтә алар:
«Бу малай нишләп тора?»

Маршрут транспорт чарасы да
Выҗылдап узып китә!
Әйтегезче, бу кешеләр,
Чыкмыйча, нәрсә көтә?!

Менә берзаман бар халык,
Юл аша чыгып китте.
Әни дә, мине җитәкләп,
Алга таба юнәлде.

Яхшылап карасам өскә,
Күрдем! Менә икән эш нидә!
Светофор сигналын биреп,
Юл күрсәтә бит өстә!

Хәзер яна светофорның
Яшел сигналы безгә!
Борылып мин дә күзне кыстым
Туктаган автомобильгә.

Үзем искә төшерәм
Светофорның сигналын:
Кызыл сигнал туктата,
Яшел сигнал юл ача.

Ә автомобильдә йөргәнгә,
Сары сигнал көттерә.
Бераз гына сабыр ит дип,
Аңлата ул кешегә...

Әни мине җитәкләгән,
Мин дөньясын тикшерәм.
Юл билгеләрен эзлим
Һәм төшерәм исемә.

Күрәм: алда зәңгәр шакмак,
Ак кеше аска бара.
Әнием дә алып чыкты,
Җир асты юлы аша.

Мәктәпне күрәм һәм күрәм мин,
Күпме билге кисәтә!
Кемнең кая барасын да
Әллә чынлап күрсәтә!?

Бу чатта кызыл түгәрәк,
Эчендә сызылган аның кеше!
Җәяүлегә йөрмәскә ди,
Бу юл автомобиль өчен!

Ә бу билге, киресенчә,
Йөртүчене кисәтә.
Игътибарлы булырга өнди
Җәяүле үткән чакта.

Кызыл түгәрәк эчендә
Ак төсле турыпочмак.
Юл юк диеп кисәтә ул
Бераз гына алданрак.

Аеруча сак булырга
Куша торган билге бар!
Бу билгене бар да таный:
Сак булыгыз, балалар!

Карагызчы, юл искергән,
Анда төзәтү эше бара.
Билгесе дә кисәтеп
Куелган безнең алда!

Болай йөрү килешми дип,
Уйларымны тараттым!
Әниемнең кулыннан мин
Бик ныклап үзем тоттым!

Әле бик күпне белергә
Кирәк булуын беләм!
Укытучы апамны тыңлап,
Юл билгесен өйрәнәм!

Юл йөрү кагыйдәләрен
Ныклап өйрәнгән чакта,
Булырсың син чын тәртипле!
Онытма шуның хакта!

Җәяүле йөргән бер көнне
Сөйләдем әле сезгә.
Бер сөйләрмен пассажир дип,
Барганда автомобильдә!



*Рәс. 16. II урын – Газимова Л.Г., Кече яшьтәге мәктәп балалары өчен «Имин була күрсен юллар» шигърият номинациясе*

**Фикер алышу өчен сораулар:**

1) «Җәяүлеләр кичүенә» барып җиткәч, ни өчен берәү дә кузгалмый?
2) Аяз нинди юл билгеләре күргән? Алар ничәү?
3) «Җир асты юлы» билгесен Аяз ничек тасвирлый?
4) Аяз нинди нәтиҗәгә килә? Нәтиҗәсен укып күрсәтегез.
5) Шигырьне ничек дәвам итәр идегез?
6) Сез Аязны нинди итеп күз алдына китерәсез, рәсемен ясагыз.

## III урын

## Тукайга ияреп...

*«Габдулла Тукай исемендәге Арча педагогика көллияте»*
*дәүләт автономом һөнәри белем бирү учреждениесе*
*студенты Дәниф Данис улы Хәмидуллин (рәс. 23)*

Аты дигән авылда бер Әби белән Бабай торган,
Тормышлары түгәрәк, ризыклары мул булган.
Асраганнар икән, ди, бер Кәҗә белән бер Сарык,
Мырауҗан атлы песи һәм бер эт – Аккойрык.

Әйтә икән беркөн ире: «Кара монда, Хатын,
Арчада ветераннарга бирәләр икән фатир!»
Кәҗә белән Сарыкны эшмәкәрләргә бирик,
Үзебез уңайлы фатирда җай гына көн күрик.

Картлар никтер шәһәр тормышына бик кызыга –
Кәҗә белән Сарыкның гына кәефләре бозыла:
«Ә без нишлик? Әби-Бабай, бу дөрес карармы?
Туган нигезне ташлап чыгып китү ярармы?»

Мырауҗан белән Аккойрык авылда яшәп каламы?
Туган йорт кадерлеме, әллә инде фатирлы каламы?
Безнең ямьле ишегалды шулай буп-буш калырмы?
Бик матур бу гаиләбез бөтенләйгә таркалырмы?

Аптырыйлар тәмам мескен Кәҗә белән Сарык,
Булмый инде Хуҗа теләгәнгә каршы барып.
Китте болар якындагы кырга таба сәфәр чыгып,
Озатып калды Мырауҗан-Аккойрык, капканы ябып.

Ерактагы басуда эшмәкәр куе печән чәчкән,
Шәпләп тамак туйдыру исәп, печән ашап кичтән.
Шул исәп белән алга бара болар, һаман бара,
Һич күренмидер күзләренә ак һәм кара.

Кәҗә-Сарык яшел печән янына якын барса,
Мескеннәрнең күз алдында менә нәрсә:
Басудагы тәмле печәнне карап сакчы йөри,
Терлек түгел, чебен дә монда үтеп керми!

Төне бигрәк салкын икән, өзелеп тамак ачты,
Авыр уйлардан Кәҗә-Сарыкның башы катты.
Әби белән Бабай да бик нык сагындырды:
Хәл начар: ике дус та борын салындырды.

Төнне чак көчкә уздырып, алсу таң аткач,
«Инде кая барыйк?» – дип уйлап баш ваткач,
Болар затлы шәһәргә таба сәфәр китә,
Күңел җылытып, алда утлар ялт-йолт итә.

Озак баралар шунда Кәҗә белән Сарык,
Салкын чишмә сулары эчә-эчә, хәлдән таеп,
Шәһәргә кергәндә, иптәшенә әйтә Сарык:
«Әйдә, Кәҗә, май-сөт сатыйк, ярминкәгә барып!»

Сарыкның төпле киңәшенә Кәҗә күнде:
«Ярминкәгә барсак, тизрәк барыйк инде.
Тамак тук булса, күңелләр дә көр булыр,
Бәлки әле, безнең Әби-Бабай да күренер!»

Бара болар атлап, тукталмастан, һаман бара.
Кинәт күрә болар: ерак түгел генә ике ут яна!
Мескеннәрнең каршындакүренә менә нәрсә:
Ялтыр күзле бер ят Мәче кимерә әллә нәрсә!

Бик куаналар инде Кәҗә-Сарык моны күргәч,
Бу җанварның аларга зыянсыз икәнен белгәч.
Авыл песие Мыраужан кебегрәк булса юмарт,
Ризыгы белән дә бүлешә белер әле, шәт?!

Ә бу дорфа Мәче озын-озак сөйләшеп тормый,
Мескен юлчыларны татлы тәгам белән сыйлый.
Үзе Кәҗә белән Сарыкны читтәнрәк караштыра,
Җай гына, әкертенләп исеме белән таныштыра:

«Шәһәр мәчесе булам мин,Фара исемле үзем,
Олы юллардан бик сакланып кына йөрим.
Автомобильне дә, җәяүлене дә бик тиз күрәм,
Хәвеф-хәтәрсез йөримен, үтә игътибарлыга күрә.

Сөйләсәм сөйлим инде, мине мактана димәгез,
Һәр сүземне уенга алып һич тә көлмәгез!
Минем күзләрем караңгыда яктылык кайтара,
Менә шуңа кыю йөри беләм әллә кайларда!

Күземнең бу үзенчәлеген күптән күреп белгәннәр:
Белгеч-галимнәр менә нинди файда керткәннәр:
Хәзер һәрбер юл билгесе караңгыда яктылык кайтара,
Күзләрем күк фликерлар җемелди хәзер балаларда!»

Кәҗә-Сарык хәйран калып Фараны тыңлап тора,
Мут күзле Фара гайрәт чәчеп кагыйдә аңлата:
«Ярминкәгә таба барганчы,башта юл билгесен бел!
Сездәй ваемсызларга олы юлда куркыныч була гел!

Юл билгесе караңгыда да яктылык кайтара –
Ә менә сезнең тиешле фликерларыгыз кая?
Шәһәрдәге һәрбер трамвай һәм троллейбус –
Кагыйдә үтәүче җәяүле белән генә була дус!»

Кәҗә белән Сарык туган авылны сагына,
«Мыраужан янына озат», – диеп,Фарага ялына.
Көяз Фара дуслар табылуга үзе дә бик шат:
Мыраужан белән күрешер әле, авылда булса кунак!

Дуслар сак кына атлап шәһәрдән чыгып китә,
Ә туган авылда аларны зууур яңалык көтә:
Бар җирдә дә карантин игълан иткәннәр –
Шуңа яше-карты авылга кайтып җиткәннәр!

Әби белән Бабай да утыра капка төбендә,
Кәҗә-Сарыкны көтеп, юлда икесенең күзе дә.
Мыраужан Фараны шатланып каршы ала,
Әби бик сөенә, кунакларын сыйлап сөт сала.

Аккойрык дус йортны бик әйбәт барлаган:
Ишегалды һәм бакчада тәртип саклаган.
Яшелчә һәм җиләк-җимеш – бар ризык та мул!
Нинди зур бәхет бит ул исән йөреп сау кайту!
Күңел тыныч булганда,тормышлар да җайлана:
Кагыйдә белеп сак йөрүчеләр генә алга бара.
Әкияттәге Кәҗә-Сарык, Мәче-эттән үрнәк ала-ала,
Гел кагыйдә өйрән, юлда сак йөр син дә, әй бала!




*Рәс. 17. III урын – Хәмидуллин Д.Д., Кече яшьтәге мәктәп балалары өчен «Имин була күрсен юллар» шигърият номинациясе*

**Фикер алышу өчен сораулар:**

1) Нәрсә ул фликер? Ул ни өчен кулланыла?

2) Кәҗә-Сарык, шәһәр мәчесе Фара – җәяүләп хәрәкәт итүчеләр. Җәяүлеләр үтәргә тиешле кагыйдәләрне әйтегез.

3) Әкиятнең авторы балаларга нинди киңәш әйтергә тели? Шигырьнең шул юлларын укып күрсәтегез.

4) Сез Кәҗә-Сарыкны, шәһәр мәчесе Фараны нинди итеп күз алдына китерәсез, рәсемен ясагыз.

# Кече яшьтәге мәктәп балалары өчен «Имин була күрсен юллар» шигърият номинациясе лауреатлары

## Нәниләргә нәсыйхәт

*Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының*
*«З. Т. Шәрәфетдинов исемендәге Карасу төп гомуми белем бирү мәктәбе»*
*муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең*
*татар теле һәм әдәбияты укытучысы*
*Камалетдинова Диана Фоат кызы (рәс. 18)*

Нәни дустым! Чыгып чапма
Барып җитим дип тизрәк.
Юл йөрү кагыйдәләрен
Һәркемгә белү кирәк.

Юлда каршы алыр сине
Кисәтүче билгеләр.
Алар хәвеф-хәтәрләрдән
Сак була күр син, – диләр.

Юл чатларына тезелгән
Өстенлек билгеләре.
Баштан бу кеше үтә ди,
Аннары бүтәннәре.

Тыю билгеләре дә бар
Син үтәсе юлларда.
Шуңа күрә чикләүләрне
Һич исеңнән чыгарма.

Йөреш, хәрәкәт, баруның
Алышыну тәртибен
Күрсәтмәләр хәбәр итә –
Аңларга тиеш үзең.

Мәгълүмати билгеләрне
Игътибарсыз калдырма.
Журналларда гына түгел
Юлларда да чагыла.

Ярдәм итү пунктлары
Күрсәтелгән билгеләр:
– Эзләп йөрмә син интегеп,
Безгә карап бел, – диләр.

Мәктәпкә барырга ярый
Өлкәннәр белән генә.
Имин була күрсен юллар,
Гомер ул бирәү генә.



*Рәс. 18. Камалетдинова Д.Ф., Кече яшьтәге мәктәп балалары өчен «Имин була күрсен юллар» шигърият номинациясе лауреаты*

**Фикер алышу өчен сораулар:**

1) Нәсыйхәт сүзенең мәгънәсен ничек аңлыйсыз? Бу сүзне тагын нинди сүзләр белән алыштырып була (синонимнарын табыгыз)?

2) Юл йөрү кагыйдәләрен ни өчен һәркем белергә тиеш?

3) Үзегез яшәгән тирәлектә булган юл билгеләрен атагыз яисә рәсемнәр арасыннан сайлап алыгыз (күрсәтмә материал кулланыла).

4) Проекторда яисә тактага беркетелгән юл билгеләрен төркемнәргә аерыгыз (кисәтүче, өстенлек, тыю, күрсәтмәләр, мәгълүмати, ярдәм итү пунктлары). Һәрберсенә аңлатма бирегез.

5) Юлда йөргәндә, нинди саклык чаралары күрергә кирәк?

6) Әти-әниләрен яисә өлкәннәрне тыңламаган балаларга нинди киңәшләр бирер идегез?

7) Юлда йөрүне китап уку белән чагыштырып буламы? Ни өчен була яисә булмый?

9) «Күрсәтмәләр хәбәр итә – аңларга тиеш үзең» дигән гыйбарәне ничек аңлыйсыз? Ни сәбәпле юлда хәрәкәт итү өчен билгеле бер күнекмәләр кирәк? Бер нинди кагыйдә дә белмичә юлга чыгып китәргә ярыймы?

10) Тыю билгеләре нәрсәгә кирәк? Юллардан тыю билгеләрен алу нинди нәтиҗәгә китерергә мөмкин?

11) Юлларда нинди ярдәмгә мохтаҗлык туарга мөмкин? Ярдәм итү пунктларының әһәмиятен аңлатыгыз.

12) Юл иминлеген саклау хезмәтендә кемнәр эшли? Юл хәрәкәте иминлеге хезмәткәре нинди сыйфатларга ия булырга тиеш? Сез юл иминлеген саклау өлкәсендә эшләр идегезме?

13) «Бәхетле очрак» дигән темага, юл йөрү кагыйдәләрен кулланып, 5–10 җөмләле инша языгыз.

## Әбием теләкләре

*«Юл хәрәкәте иминлеге» дәүләт бюджет учреждениесе*
*Яр Чаллы шәһәре территориаль идарәсе профилактика бүлегенең*
*әйдәп баручы белгече Рамил Рәҗәп улы Мирзаянов*

Шөкер, димен исән булганыма,
Бар бит ашарыма, өстемә кияргә,
Рәхмәт димен иртән уянганыма,
Онытмыйк «Аллага шөкер» диярге!

Туганнарым һәрчак янәшемдә!
Сакла, Аллаһы Тәгаләкәем, берүк аларны!
Каермыйча парлы канатларны,
Бәхетле ит, Ходаем, минем баламны!

Көннәр имин булсын, уң булсын эшем.
Хәвеф-хәтәр була күрмәсен,
Бу дөньяга килгән һәрбер кеше –
Кайгы-хәсрәт тәмен белмәсен.

Югалтулар бигрәк ачы була,
Сакла, Аллаһы Тәгаләкәем, юлда йөргәндә...
Ашыкмагыз! Сак булыгыз, ди
Җилкәдәге фәрештәләр һәммәбезгә!

Тик кайберегез ишетмисез!.. Нигә?!
Фәрештәләр безне саклый менә!
Кагыйдәләр безгә түгел – кирәк алар СЕЗГЭ!
Шулай диеп көлә-көлә, ялгышалар күпләр,

Кайберәүләр ялгышалар, тик ялгышалар алар бер генә...
Бу ялгышу, юл кагыйдәләрен хөрмәт итмәү
Китермәсен үкенечкә,
Исеңдә тот! Гомер ул – берәү...

Әгәр гүргә китсәң – теге дөньялардан булмый кире кайтып!
Хәтта булмый хәл белергә генә дип шалтыратып...
Сак булыгыз! Имин булсын юлларыгыз!
Мин дә «крутой» дип кабатлап ялгышмагыз!
Бер-беребезне юлда хөрмәт итик,
Шулчакта гына булыр юлда тәртип!

## Ярдәмче инспектор

Бабай тора юлда,
Чатны ничек чыгарга?
Тирә-якка карый ул,
Тегендә дә, монда да.

Светофор яна, сүнә,
Бабай өметен өзә –
Нәкъ шул вакыт бабайга
Килә берәү ярдәмгә.

– Бабай, хәзер бер минут,
Юл аша үтәрбез.
Хәзер янды яшел сигнал,
Әйдә, бабай чыгабыз!

Бабай куйды шатланып,
– Килде ярдәм Алладан,
Инспектор да макталып,
Алды рәхмәт бабайдан.

## САКЛА.РУ

*Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының*
*«Ләйсән» балалар бакчасы»*
*муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем учреждениесе*
*мөдире Диләрә Хәмит кызы Кашапова*

САКЛА.РУ сайтына бүген
Керсәгез, бик күңелле!
Без белмәгән әкиятләр
Монда гына билгеле!
Төрле-төрле юл хәлләре,
Рәсем ясау, шигырьләр,
Балалар өчен бәйгеләр,
Кызыклы мәкаләләр!
Барыгызга тәкъдим итәм,
Теркәлү җиңел үтә.
САКЛА.РУ сайты һәркөнне
Сак булырга өйрәтә!

# ФОТОРЕПОРТАЖ



*Рәс. 19. Шагыйрьләр Рүзәл Мөхәммәтшин, Галимҗан Гыйльманов, «Салават күпере» һәм «Сабантуй» журналларының баш мөхәррире Зилә Хөснетдинова мастер-класс алып баралар*



*Рәс. 20. «Яшел сигналга сәяхәт» татар телендә яшь язучыларның Республика конкурсы финалистлары*



*Рәс. 21. Иҗат мәктәбе эше*



*Рәс. 22. Татарстан Республикасы мәктәпкәчә белем бирү оешмаларының балаларны юлларда иминлек кагыйдәләренә өйрәтү буенча эшләренең тематик күргәзмәсе*



*Рәс. 23. Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры урынбасары Минзәлия Заһри кызы Закирова һәм Казан дәүләт мәдәният институты ректоры Роза Шәйхәйдәр кызы Әхмәдиева күргәзмәне карыйлар*



*Рәс. 24. «Юл хәрәкәте иминлеге» дәүләт бюджет учреждениесе директоры Рифкат Нургали улы Миңнеханов һәм «Тормыш иминлеге фәнни үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе директоры Евгения Евгеньевна Воронина күргәзмәне карыйлар*



*Рәс. 25. «Юл хәрәкәте иминлеге» дәүләт бюджет учреждениесе Казан шәһәре территориаль идарәсенең профилактика бүлеге начальнигы Любовь Тимофеевна Ананьичева тематик күргәзмә турында сөйли*



*Рәс. 26. Казан дәүләт мәдәният институты китапханәсенең татар телендә балалар өчен һәм укыту-методик китаплар күргәзмәсе*



*Рәс. 27. «Тормыш иминлеге фәнни үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенең рус һәм татар телләрендә балалар өчен һәм укыту-методик китаплар күргәзмәсе*







*Рәс. 28. Казан шәһәре Совет районының 177нче катнаш төрдәге балалар бакчасында тәрбияләнүчеләр күргәзмәне карыйлар*



*Рәс. 29. «Яшел сигналга сәяхәт» татар телендә яшь шагыйрьләр һәм язучыларның Республика конкурсының тантаналы бүләкләү чарасы «Туган тел» җыры белән ачылды. Җиңүчеләр һәм дәрәҗәле кунаклар өчен иҗади номерны Казан дәүләт мәдәният институты педагоглары һәм студентлары башкардылар*



*Рәс. 30. Алып баручылар республика конкурсы турында сөйлиләр*



*Рәс. 31. Җиңүчеләр һәм дәрәҗәле кунаклар өчен иҗади номерны Казан шәһәре Совет районының 177 нче катнаш төрдәге балалар бакчасында тәрбияләнүчеләр башкардылар*



*Рәс. 32. Сәламләү сүзе белән «Юл хәрәкәте иминлеге» дәүләт бюджет учреждениесе директоры Рифкат Нургали улы Миңнеханов чыгыш ясады*



*Рәс. 33. Җиңүчеләр һәм дәрәҗәле кунаклар өчен иҗади номерны «Юл хәрәкәте иминлеге» дәүләт бюджет учреждениесе хезмәткәрләре башкардылар. «Әтнә кичләре» биюе*



*Рәс. 34. Сәламләү сүзе белән Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министры урынбасары Минзәлия Заһри кызы Закирова чыгыш ясады*



*Рәс. 35. Җиңүчеләр һәм дәрәҗәле кунаклар өчен иҗади номерны Казан дәүләт мәдәният институты педагоглары һәм студентлары башкардылар. «Топотуха» биюе*



*Рәс. 36. Казан дәүләт мәдәният институты педагогы Алсу Рөстәм кызы Зәйнетдинова (АсылЯР) «Нурлы Казан» җырын башкарды*



*Рәс. 37. Җиңүчеләр һәм дәрәҗәле кунаклар өчен иҗади номерны Казан дәүләт мәдәният институты педагоглары һәм студентлары башкардылар. «Красавчик» җыры*



*Рәс. 38. Сәламләү сүзе белән Казан дәүләт мәдәният институты ректоры Роза Шәйхәйдәр кызы Әхмәдиева чыгыш ясады*



*Рәс. 39. Казан дәүләт мәдәният институты педагогы Айнур Моратов традицион татар уен кораллары яңгыравын күрсәтте*




*Рәс. 40. Казан дәүләт мәдәният институты доценты Эльвира Ризван кызы Гиматдинова студентлар белән «Татарстан» җырын башкарды*



*Рәс. 41. «Яшел сигналга сәяхәт» Республика конкурсы җиңүчеләре*

# ЯШЕЛ СИГНАЛГА СӘЯХӘТ

татар телендә иҗат итүче яшь шагыйрьләр һәм язучылар
Республика конкурсы нәтиҗәләре буенча
җиңүчеләрнең иҗади эшләре җыентыгы

Р. Н. Миңнеханов,  Н. И. Рәхмәтуллина гомуми редакциясендә

Мөхәррире С.Г. Галиева
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучысы Л.А. Ризванова
Корректорлары Ч. Ялалова

«Тормыш иминлеге фәнни үзәге»
дәүләт бюджет учреждениесе нәшрияты
420059 Казан шәһәре, Оренбург тракты, 5.
Оригинал-макеттан басарга кул куелды      .
Шартлы басма табагы
Форматы 60×90/16. Тиражы  д.
ООО басылган.